• СОРАУ-ҖАВАП •
INSTAGRAMДА БӘЙГЕЛӘР УЗДЫРУ
7 бит

• СӘЛАМӘТЛЕК •
КОРОНАВИРУСКА КАРАТА НӘЗАРӘТ ТӘКЪДИМНӘРЕ
10 бит

• ТӘРБИЯ •
КЕШЕ – ГӨНАҺ КЫЛУЧАН ЗАТ
12 бит

• СӨННӘТ ГАМӘЛ •
АХИРӘТ ГАЗАБЫ ДӨНЬЯ ГАЗАБЫННАН КАТЫРАК
14 бит


№ 3 (296) | Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы | Раҗәб – шәгъбан 1441

Март, 2020

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Мөбарәк шәгъбан аена аяк бастык



Аны «Ләйләтел-Бәраәт» дип атыйлар. «Ләйләтел-Бәраәт»нең мәгънәсе «пакьләнү», «бурычтан вә җәзадан котылу» дип аңлатыла. Безгә дә бу кичәдә Аллаһының ярлыкавына, мәгъфирәтенә ирешер өчен нишләргә кирәк соң?

Тулырак 8 нче биттә

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Ш.Мәрҗани музее нәзарәтнең «Даруль-кутуб» электрон китапханәсенә борынгы китаплар тапшырды


Darul-Kutub.com татар дини мирасының электрон китапханәсе Мәрҗани музей-йорты коллекциясеннән борынгы басмалар алды. Әлеге китаплар алга таба сайтта урнаштыру өчен Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте «Хозур» нәшрият йорты белгечләре тарафыннан сканер аша үтәчәк.

Беренче этапта ислам дөньясының күренекле дин эшлеклеләре, хәнәфи мәзһәбе галимнәре Ибне Габидин һәм Фәхретдин Хәсән Әл-Үзгенди хезмәтләрен сканер аша үткәрергә кирәк булачак. Госманлы империясенең иң абруйлы мөселман хокук белгечләренең берсе булган имам Ибне Габидин китабы – «Радд әл-Мохтәр галә әд-Дурр әл-Мохтәр» күптомлы әсәренең өченче томы. Бу хезмәт хәнәфи мәзһәбе буенча иң яхшы китап булып санала. Фәхретдин Әл-Үзгенди хезмәте – танылган «әл-Фәтва әл-Һиндия» трактатының өченче томы. Бу китапта сәүдә, залог, хөкем чыгару мәсьәләләре һәм башкалар җентекләп тикшерелә. «Даруль-кутуб» белгечләре бирелгән китапларның һәркайсы буенча кыскача аннотация әзерләде.

Коллекциянең төп байлыгын мәшһүр татар мөфтие һәм мәгърифәтче, Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә нигез салучы һәм аның беренче ректоры Галимҗан Барудиның шәхси китапханәсеннән булган хезмәтләр тәшкил итә.

«Мәрҗани музей-йорты белән хезмәттәшлек итү Рәсәй мөселманнарына татар халкының бай дини мирасын өйрәнүдә өстәмә этәргеч булуына ышанабыз, – дип билгеле Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Даруль-кутуб» проекты җитәкчесе Исмәгыйль Нәшырбанов. – Без һәрбер кеше үзенә кирәкле булган, сирәк очрый торган китапларны таба алсын өчен тырышабыз». Шиһабетдин Мәрҗани музей-йорты Казанда Каюм Насыйри ур., 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан. Хәзерге вакытта биредә төзекләндерү эшләре алып барыла.

Исегезгә төшерәбез: Darul-Kutub редакциясе шәхси китапханәләрдә сакланган хезмәтләрне Нәзарәтнең «Хозур» Нәшрият йортына тапшырырга чакыра. Биредә аларны шулай ук сканер аша уздырып сайтка куячаклар. Китаплар кире кайтарыла. Дини мирасны саклауга һәм таратуга өлеш кертергә ашыгыгыз!



Китапларны түбәндәге адрес буенча алып килергә мөмкин: Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт, «Хозур» нәшрият йорты.

Элемтә өчен телефон: 8 (843) 598-09-39, электрон почта: kutub@huzur.ru

Darul-Kutub.com – уникаль дини басмаларның электрон архивы. Төп максат – татар дини мирасын саклау, аны өйрәнү һәм тәрҗемә итү, традицион булмаган ислам формаларының үтеп керүен профилактикалау, дин кардәшләребезнә хәнәфи мәзһәбенең абруйлы чыганаклары белән таныштыру. 2017 елда сайтның яңартылган версиясе эшли башлады. Әлеге проектны Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты алып бара.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Чаллыда «Җәмгыять тормышын тотрыклындыруда Ислам диненең әһәмияте» дип исемләнгән V Халыкара фәнни-гамәли конференция узды

14 нче мартта Чаллыдагы «Ак мәчет» мәдрәсәсендә «Җәмгыять тормышын тотрыклындыруда Ислам диненең әһәмияте» дип исемләнгән V Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте.

Конференция эшендә Чаллы шәһәре имаммөхтәсибе Әлфәт хәзрәт Гайфуллин, Татарстанның Кама буе төбәге казые һәм «Ак мәчет» мәдрәсәсе директоры Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев, сәясәт фәннәре кандидаты, ТР Фәннәр академиясенең Ислам тикшеренүләре үзәге директоры Ринат Патеев, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе директоры урынбасары Зөлфәт хәзрәт Габдуллин, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор, Мәскәү лингвистика университетының фәлсәфә фәннәре кафедрасы мөдире Айдар Каюмов, фән докторы, Мерсинский университеты профессоры Дүрмүш Гали Арслан һәм башкалар катнашты.

Конференция «Ислам һәм фән», «XXI гасырда конфессияара хезмәттәшлек», «Патриотлык тәрбияләүдә рухи традицияләрнең роле», «Яшьләрне рухи-әхлакый тәрбияләүнең нигезе буларак дин», «Хәзерге Рәсәй җәмгыятенең кыйммәтләре системасында дин» кебек темаларга багышланды.



■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Мөфти I Бөтенроссия ришвәтчелеккә каршы яшьләр форумы эшендә катнашты

12 нче март көнне Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «PROкоррупцию ПРОсто» дип аталган I Бөтенроссия яшьләр форумында катнашты. Әлеге чарада ТР дәүләт хакимияте органнары җитәкчеләре, Дәүләт Советы депутатлары, республикабызның югары уку йортлары вәкилләре, бизнес-структуралар җитәкчеләре, шулай ук ТР Яшьләр хөкүмәтеннән, Иҗади яшьләр академиясеннән, ТР Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасыннан һәм башка яшьләр иҗтимагый оешмаларыннан 140 кеше катнашты.

Әлеге форум кысаларында РФ субъектларының яшьләр хөкүмәте һәм яшьләр оешмалары активистлары ришвәтчелеккә каршы көрәш буенча иҗтимагый оешмалар эшен тәкъдир иттеләр. Форум Рәсәйдә яшьләр арасында ришвәтчелек проблемасын уртак хәл итүнең башлангыч ноктасы булачак.

■ dumrt.ru сайтыннан



# Нәзарәттә Татарстанның дини оешмаларында коронавирус таралуны булдырмау чаралары кабул ителде

18 нче март көнне Казанда ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы утырышы узды. Татарстанның дини оешмаларында коронавирус таралуны булдырмау чараларын күрү – көн тәртибендә төп мәсьәлә шул булды. Аны кичә көндез нәзарәтнең Президиум әгъзалары да тәфсилләп өйрәнде: утырышта мөфтият җитәкчелеге, Татарстан имам-мөхтәсибләре, Голәмәләр шурасы әгъзалары, нәзарәтнең бүлек җитәкчеләре катнашты.

Нәтиҗәдә, Президиум тәкъдимнәрен игътибарга алып, Татарстанның мөселман дини оешмаларында инфекция таралуны булдырмау максатыннан Голәмәләр шурасы тарафыннан берничә карар кабул ителде.

Голәмәләр шурасы әгъзалары Кытайда, Мисырда, Иранда, Италиядә, Франциядә, Испаниядә һәм башка дәүләтләрдә коронавирус инфекциясеннән вафат булучыларның якыннарының һәм туганнарының кайгысын уртаклаша. Шура әгъзалары шулай ук дин кардәшләрне игътибарлы һәм сак булырга, тынычлыкны сакларга чакыра.

Мөселман кешесе коткыга һәм куркуга бирелергә тиеш түгел. Шуның белән бергә инфекциягә җиңел карау, табибларның күрсәтмәләрен үтәмәү, үзеңне һәм әйләнә-тирәдәгеләрне вирус йоктыру куркынычына дучар итеп, профилактик чараларны кире кагырга да ярамый.

Коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, ислам хокукының төп принципларына таянып, Шура әгъзалары тарафыннан түбәндәге вакытлыча тәкъдимнәр кабул ителде:

1. Намазга чакыруны (азан) гадәттәгечә үтәргә, намаз башлану турында игъланны (камәт) азаннан соң ук әйтергә, җәмәгать белән намаз укуны бары мәчет хезмәткәрләре (имам, мөәзин, кизү торучы зат) катнашында гына башкарырга.

2. Мәхәллә кешеләре өчен мәчетләрдә һәм намаз бүлмәләрендә индивидуаль рәвештә (җәмәгать белән түгел) биш вакыт намаз уку мөмкинлеген оештырырга.

3. Җомга намазын башкарганда фарыз гамәлләр белән чикләнү: җомганың мәҗбүри гарәп телле хотбәсен озакка сузмыйча (3-5 минут) һәм ике рәкәгать намаз укырга.

4. Иммунитеты көчсезләнгән, сәламәтлеге какшаудан курыккан дин кардәшләргә массакүләм дини чараларга, шул исәптән җомга намазларына бару киңәш ителми, шул рәвешчә җәмәгать намазларыннан тыелып торуны гөнаһ кылу дип санамаска.



5. Мәҗлесләрне, никах һәм исем кушу мәҗлесләрен дә, күп кеше катнашында оештыру гадәтен туктатып торырга.

6. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәчетләрендә, намаз бүлмәләрендә һәм уку йортларында белем бирү һәм тәрбия чараларын уздыруны туктатырга.

7. Мөмкин булганча, кул биреп һәм кочаклашып башкарыла торган традицион дини сәламләшүдән тыелып торырга.

8. Җеназа намазларын ачык һавада мөмкин кадәр азрак кеше катнашында үткәрергә.

9. ТР мөселманнары Диния нәзарәте структурасына керә торган барлык мәчетләргә, гыйбадәт кылу бүлмәләренә, уку йортларына һәм оешмаларга кабул ителгән тәкъдимнәр буенча хәбәр бирүне оештырырга.

10. Санап үтелгән әлеге тәкъдимнәрне 2020 елның 15 апреленә кадәр яисә башка карарлар кабул ителгәнчегә кадәр гамәлдә дип санарга.

■ dumrt.ru сайтыннан

# Рамазан аен каршы алабыз

**«Рамазан ае – кешеләргә туры юл һәм дөреслекне ялганнан аера торган дәлилләре булган Коръән иңгән ай. Сезнең кайсыгыз шул айда әзер булса, әлбәттә, ураза тотсын. Әгәр берәү авыру яки сәфәрдә булса, аңа башка көннәрдә шул ук санда ураза тотарга кирәк. Аллаһы җиңеллек тели, авырлык теләми. Боларны, санны төгәлләү өчен, туры юлга салу өчен, Аллаһыга шөкрана итүегез өчен эшләдек».**

«Әл-Бәкара», 2:185

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдис-шәрифендә:

«Һәрнәрсәнең зәкяте, ягъни пакьләүчесе була. Тәннең зәкяте – ураза», – дип әйткән. Рамазан аенда, таң яктылыгы җәелгән вакыттан башлап, кояш батканчыга кадәр, балигъ һәм акылы булган һәрбер мөэмин кешегә ашамыйча, эчмичә һәм якынлык кылмыйча тору – фарыз.

Ураза тотуның фарызлары өчәү:

1. Ният кылу;
2. Ашау-эчүдән тыелу;
3. Якынлык кылудан тыелу.

Мөселманнар Рамазан аен изге ай дип хөрмәт итәләр. Нәкъ менә шушы айда Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә пәйгамбәрлек иңдерелгән һәм шуның белән Ислам диненең яңарышы башланган. Мең айдан хәерлерәк булган Кадер кичәсе Рамазанга туры килә.

Әлеге айда мөэминнәр ният уразаларын тоталар. Ураза кешеләрне гөнаһлардан арындыра, явыз уйфикерләрдән, яман теләкгамәлләрдән тыеп кала. Аллаһы Раббыбыз:

**«Әй, иман китергәннәр. Ураза элеккеләргә фарыз ителгән кебек, сезгә дә фарыз булды. Бәлки куркырсыз инде»,** – дип әмер иткән.

«Әл-Бәкара», 2:185

Ураза тоту, иң әһәмиятле гыйбадәт төрләренең берсе булып тора. Дөньялыкта ул безне яман эшләрдән саклый. Ә Кыямәт көнендә Аллаһы-ның гөнаһларыбызны ярлыкавына сәбәпче була, җәһәннәм утыннан коткара, ин шә Аллаһ!

Ураза тотар алдыннан ниятебез дә дөрес булырга тиеш. Уразага кергәндә түбәндәге сүзләрне укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала:

نَوَيْتُ أَنْ أَصُومَ صَوْمَ شَهْرِ رَمَضَانَ مِنَ الْفَجْرِ إِلَى الْمَغْرِبِ خَالِصًا لِلَّهِ تَعَالَى

«Нәүәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләлмәгъриби хаалисан лилләһи Тәгалә»

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен ихласлык белән, таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр, Рамазан ае уразасын тотарга ният кылдым».

Уразалы кеше көн дәвамында ашау-эчүдән, якынлык кылудан һәм дә золым гамәлләрдән тыелырга тиеш була.

Берәү карт бер абзый кешедән: «Бабай, җәй көнне Рамазан ае уразасын тота алмасам, нишләргә?» – дип сорый икән. Карт исә: «Әгәр җәй тота алмасаң, кыш тотырга була. Анда көннәр кыска, артык эше дә юк» – дип җавап бирә.

Җәмәгать, хәзер барыбызның да акылыбыз, белемебез җитәрлек. Әмма ялгыш киңәшләр биреп, фарыз гамәлләрне кичектерергә безнең хакыбыз юк. Аллаһы Тәгаләбез безгә билгеле бер вакытта үтәлә торган гамәлләрне кушкан икән, (мәсәлән, намазны үз вакытында уку, фарыз уразасын Рамазан аенда тоту) дөрес итеп үтәргә тиешлебез. Калдырсаң, өстебездә бурыч булып кала түгелме соң?! Үкенергә калмасын, Аллаһы Үзе сакласын! Каза кылып булса да үтик!

Кояш баткач, ниндидер ризык, тоз яки су белән ифтар кылу (авыз ачу) – сөннәт гамәл. Хөрмә кебек татлы җимешләр белән ифтар кылу – мөстәхәб булып тора.

Ифтардан соң түбәндәге дога укыла:

اَللَّهُمَّ لَكَ صُمْتُ وَبِكَ آمَنْتُ وَعَلَيْكَ تَوَكَّلْتُ وَعَلَى رِزْقِكَ أَفْطَرْتُ فَاغْفِرْ لِي يَا غَفَّارُ مَا قَدَّمْتُ وَمَا أَخَّرْتُ

«Аллаһуммә ләкә сумтү вә бикә әәмәнтү вә галәйкә тәүәккәлтү вә галәә ризкыйкә-фтартү фәгъфирлии йәә гаффаару мәә каддәмтү вә мәә әххартү»

Мәгънәсе: «Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым һәм Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Һәм Синең ризыгың белән авыз ачам. Әй, гөнаһларны гафу Итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».

### Ураза тоткан кешегә түбәндәге эшләр сөннәт булып санала:

1) таң атканчы, төнлә торып сәхәр ашау;

2) ураза тотып, нәфесне гөнаһлы эшләрдән тыюны ният кылу;

3) кәсептән бушаган вакытларда дини китаплар уку;

4) кояш баегач, ахшам намазын укыганчы авыз ачу.

### Ураза вакытында көндезен түбәндәге 10 төрле эшне кылу мәкруһ санала:

1) файдасыз сүзләр сөйләү;
2) әдәпсез сүзләр сөйләү;
3) мунчага кереп, озак утыру;
4) суга чумып коену;
5) ризык һәм сагыз чәйнәү;
6) берәр азыкка телне тидереп татып карау;
7) авыздан үбү;
8) ифтар кылмыйча, ике көн рәттән ураза тоту;
9) нинди дә булса бер гөнаһлы гамәл кылу;
10) авыруының артачагын белә торып ураза тоту.



### Ураза тоткан кешегә түбәндәге 6 төрле эшне башкару дөрес санала:

1) Балага ризык чәйнәп бирү (баланың ризыкны башкача кабул итү мөмкинлеге булмаганда);
2) күзгә сөрмә тарту;
3) тәһарәт вакытында мисвәк белән тешләрне пакьләү, әмма чистарткан вакытта бүленеп чыккан төкерекне һәм мисвәкнең кисәкләрен йотарга ярамый;
4) кан алдыру;
5) сөлек салдыру;
6) госел коену.

### Түбәндәге өч төрле эш уразаны боза:

1) борчак кадәр генә булса да, берәр ризык яки дару йоту;
2) бер тамчы кадәр генә булса да, су яки дару йоту;
3) якынлык кылу.

Әгәр адәм баласы Рамазан аенда белә торып берничә тапкыр уразасын бозса, бөтен очраклар өчен бер кәффарәт (гөнаһтан арыну өмете белән кылынган яки кылынырга тиешле эш) кылса, җитә. Яисә, үзе тота алмаса яки тотмаса, үзеннән фәкыйрьрәк кешене ай дәвамында ашатырга тиеш була.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә болай дип әйтелә:

«Бервакыт без Пәйгамбәребез белән бергә утырганда, аның янына ниндидер бер кеше килеп болай дип әйтте:

– Әй Аллаһының Расүле! Мин һәлак булдым!

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам:

– Ни булды сиңа? – дип сорады.

– Мин ураза вакытында хатыным белән якынлык кылдым.

– Синең азатлыкка чыгарыр өчен колларың бармы?

– Юк.

– Ике ай буе рәттән ураза тота аласыңмы?

– Юк.

– Алтмыш фәкыйрьнең тамагын туйдыра аласыңмы?

– Юк, – дип җавап кайтарды».

Әбү Һөрайра хәдисне дәвам итеп болай дип әйтте: «Шуннан соң Расүлебез галәйһиссәлам бераз вакыт тын калды. Без шул хәлдә булган чакта Пәйгамбәребезгә бер кәрзин хөрмә китерделәр. Ул: «Сорау биргән кеше кайда?» – дип сорады. Теге кеше:

– Мин монда, – дип җавап бирде.

Шуннан соң Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

– Боларны ал һәм садака итеп тарат, – дип әйтте.

– Әй Аллаһының Расүле! Мин боларны үземнән фәкыйрьрәк кешеләргә өләшергә тиешме? Аллаһы белән ант итеп әйтәмен, Мәдинә шәһәрендә минем гаиләмнән дә фәкыйрьрәк гаилә юк, – дип әйткән.

Шуннан соң Пәйгамбәребез галәйһиссәлам тешләре күренерлек итеп елмайды да, соңыннан болай диде:

– Бар, бу хөрмәләр белән үз гаиләңне туендыр».

Йә Раббым! Һәрбарчабызга да ураза тотуларыбызда җиңеллек бирсәң иде. Илләребезгә иминлек, тәннәребезгә сихәтлек насыйп итеп, ярдәмеңнән ташламасаң иде. Әмин!

**Фәнис хәзрәт Низамов**
**Аксубай районы, Яңа Дума авылы**

# Муса галәйһиссәлам кыйссасы

***(Дәвамы. Башы алдагы санда)***

### «Фиргавенгә бар – ул рөхсәт ителгәннәрнең чиген үтеп китте»

Фиргавен һәм аның халкы имансызлык һәм явызлыкта үҗәтлек күрсәтеп тормыш иткәндә, кешеләрне золым һәм явызлыктан аралап алу, Аннан башка чын илаһ юклыгын исләренә төшерү, исраиллеләрне коллыктан азат итү, аларны хак дингә күндерү өчен Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек ирештерә. Ул аңа болай дип әйтә:

**«(Менә бу ике могҗиза белән) Фиргавенгә бар (да, аны Миңа коллыкка дәгъват ит). Һичшиксез, ул (үзен Раббы дәрәҗәсенә куеп) азынды».**

«Та һа», 20:24

Муса галәйһиссәлам пәйгамбәр итеп бар халыкка җибәрелсә дә, аңа иң элек фиргавенгә барырга дигән әмер бирелгән була, чөнки ул үз халкының башлыгы, әгәр дә ул иманга килсә, бар халык та иманга килергә тиеш була.

Фиргавенгә барганчы Муса галәйһиссәлам Аллаһыдан үзенең бертуган абыйсы Һарунны ярдәмче иптәш итеп бергә җибәрүен сорый.

Ике бертуган арасында иң тәкъвалысы Муса галәйһиссәлам була. Абыйсы энесенә дөнья мәшәкатьләрендә ярдәмче, теләсә нинди дөнья байлыкларына ирешкәндә арадашчы була ала, тик бернинди туган да беркемгә дә пәйгамбәр булырга ярдәм итә алмый. Шулай да Муса галәйһиссәлам шуны сорап дога кыла һәм ул дога кабул ителеп, аның бертуганына пәйгамбәрлек ирештерелә.

Доганың кабул ителүе һәм Һарун галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек ирештерелүе турында Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«И Муса! Сораганнарың сиңа бирелде инде»,**

«Та һа», 20:36

**«Мин сине Үзем өчен сайладым. Син һәм кардәшең (сезгә бирелгән могҗиза һәм) аятьләрем белән барыгыз. Әммә зикерем хосусында йомшаклык күрсәтмәгез».**

«Та һа», 20:41-42

Аллаһы Тәгаләнең шул әмерен үтәп, Муса галәйһиссәлам һәм Һарун галәйһиссәлам фиргавен сараена бара. Ишек шакыган вакытта сарай әһелләре каеф-сафа корып, күңел ачып яткан була. Муса галәйһиссәлам һәм Һарун галәйһиссәламне фиргавен янына алып керәләр.

Муса галәйһиссәлам: «Ий фиргавен! Хактыр ки, мин – дөньялар Раббысының сиңа җибәрелгән расүлемен. Иманга кил, хак юлга кер һәм котылып кал! Әгәр дә иманга килмәсәң, исраиллеләрне булса да азат ит. Һәм миңа алар белән Фәләстыйнга, аларның ата-бабалары җиренә кире кайтырга рөхсәт ит, аларга явызлык кылма!» – дип әйтә.

Ул тагын үзенең пәйгамбәрлеген раслый торган могҗизалар белән килүен дә әйтә. Моңа җавап итеп фиргавен: «Әгәр дә син могҗизалар белән килгәнсең икән, күрсәт аларны», – ди.

Шуннан соң Муса галәйһиссәлам кулындагы таякны идәнгә ташлый. Ул таяк бик зур еланга әйләнә, моны барысы да күрә. Елан бик зур ерткыч хайванга яки аждаһага охшаган була. Таякның Муса галәйһиссәлам кулы белән тоткан урыны ул аждаһаның ялына әйләнә, ә ул ялның һәр кылы – сөңге кадәр була. Бу ерткыч – буаз дөя зурлыгында булып, бик зур ташларны да кабып йотарлык хәлдә була. Елан авызын ачкан вакытта башының ас өлеше сарай идәненә тиеп торса, өске өлеше – түшәмгә тия яза. Аны күргәч, кешеләрнең коты оча, алар куркып чыгып чабалар. Берничә кеше тапталып үлә. Шулай ук фиргавен үзе дә бик нык куркуга кала. Аннары Изге Китабыбызда:

**«Янә кулын (куеныннан) чыгарды, кинәт ул караучылар өчен (гадәттән тыш нурлар чәчеп, күзләрне камаштырган һәм офыкны каплаган) ап-ак иде»,** – дип әйтелә.

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:33

Муса галәйһиссәлам кулын култык астыннан тартып чыгаргач аның бу кулы бер нур сибеп, барысын да яктыртып тора башлый. Бу яктылыктан кешеләрнең күзләре камаша. Фиргавен һәм аның якыннары нык куркуга калалар, алар Муса галәйһиссәламне ялганчы дип атыйлар һәм сихерчелектә гаепләләр:

**«Һичшиксез, бу – (сихер гыйлемендә иң югары ноктага ирешкән) бик белемле сихерче. Ул сезне (Мисырда яшәп яткан) туфрагыгыздан сихере белән чыгарырга тели».**

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:34-35

### Муса галәйһиссәламнең сихерчеләр белән очрашуы

Фиргавен Муса галәйһиссәламне сихерчелектә гаепләп, шул ук коралны – сихерне кулланып аны җиңмәкче була. Муса галәйһиссәламнең кешеләр арасында абруен төшереп, үз хакимлеген ныгыту өчен фиргавен Мисырның бар сихерчеләрен җыярга әмер бирә. Моның өчен илнең бар тарафларына сөрәнчеләр җибәрелә.

Игъланны ишеткәч, Мисырның бар җирләреннән дә башкалага сихер белән эш итә белүчеләр җыела. Иң оста, иң булдыклы сихерчеләрнең барысын да җыялар.

Башкалада өч мең тирәсе тылсымчы җыела. Икенче бер риваятьтә унбиш меңгә кадәр диелә. Ничек кенә булмасын, аларның тулы бер гаскәре җыелды дип әйтергә була.

**«Сихерчеләр фиргавенгә килгәч: «Әгәр дә без җиңүчеләр булсак, безгә бер түләү булырмы?» – диделәр. Ул: «Әйе! Ул тәкъдирдә сез (түләү алу белән генә калмыйча, хозурыма иң алдан кергән һәм иң соңыннан чыккан) якын ителгәннәрдән булачаксыз», – диде».**

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:41-42

Аннан алдарак, кемгә каршы ярыш булачагын белү өчен, сихерчеләр Муса галәйһиссәлам белән очрашалар. Муса галәйһиссәлам:

– Мин сихерче түгел, ә Аллаһының расүле. Мин сезне иман китерергә өндим, – дип аларны хак дингә чакыра.

Аңа җавап итеп сихерчеләр болай дип әйтә:

– Синең пәйгамбәрме әллә сихерчеме икәнлегеңне без очрашуда белербез. Әгәр дә син үзең әйткән кеше булсаң – яхшы, ә әгәр дә бу алай булмаса, син безнең ни эшләгәнне күрерсең әле.

Очрашу көне килеп җитә. Кешеләр төркем-төркем булып шәһәр читендәге зур кырга агылалар. Фиргавен өчен тәхет эшләп куелган була, ул шул тәхетеннән тамашаны манзара кыла. Сихерчеләр бауларын, арканнарын, тиредән эшләнгән юан каеш бәйләрен тотып үзләренең осталыкларын күрсәтергә әзерләнәләр. Аларның эче куыш һәм анда терекөмеш тутырылган таяклары да була.

Менә инде барысы да көткән кеше үзе килеп җитә. Муса галәйһиссәламнең кулында таяк була, аның янәшәсендә Һарун галәйһиссәлам дә килә. Алар унбиш мең сихерчегә икәү генә каршы торалар, ләкин алар икесе дә Аллаһы бәндәләре була.

Әлбәттә, мондый хәл сихерчеләргә нык тәэсир итә. Әгәр нур сибә алучы бу кешенең максаты акча, җәмгыятьтә тоткан урын, хакимлек булса, ул фиргавен янына килеп аның белән килешеп үзе теләгәнне бик җиңел ала алган булыр иде, Фиргавенгә бу кадәр халыкка акча түләп торырга туры килмәс иде, димәк, бу кеше дөнья байлыкларына омтылмый, дип аек акыл белән фикерлиләр алар. Аннан тыш, ул фиргавеннең үзе белән үк алышка чыккан икән, мондый алыш буш һәм нигезсез түгел инде. Ә бит фиргавен зур хакимлеккә ия, аның каршында бар кешеләр дә калтырап торалар, дигән уйлар да башларына килә башлый. Шулай итеп, сихерчеләр: «Ярышны башлыйк, бу кешенең чынлап та кем икәнлеген шунда күрербез», – диләр.

Сихерчеләр болай дип әйтәләр:

**«Ий Муса, син әүвәл ташлыйсыңмы таягыңны яки әүвәл без ташлыйкмы?»**

«Та һа», 20:65

Ә Муса галәйһиссәлам:

**«Юк, (мин алдан ыргытмыйм) сез ыргытыгыз», – диде. (Алар һөнәрләрен күрсәткәч) Сихерләре сәбәпле (гүя) җепләре вә таяклары аңа (чын еланнар булып) хәрәкәтләнгән кебек күренде».**

«Та һа», 20:66

Муса галәйһиссәлам: «Таякларыгызны сез ташлагыз», – дигәч, сихерчеләр үзләре әзерләп килгән әйберләрен җиргә ташлыйлар. Аларның тиредән эшләнеп тышы майланган баулары кояшта ялтырый башлый, эченә терекөмеш тутырылган таяклары хәрәкәтләнә башлаган кебек тоела. Халыкка хәрәкәтләнеп, шуышып йөргән меңләгән еланнар белән бар кыр тулган кебек күренә башлый. Ярышны карарга килгән кешеләрнең коты алына. Моны күргәч Муса галәйһиссәламне дә эчтән курку биләп ала:

**«Муса күңелендә бер курку сизде. Без әйттек: «(Аларның сиңа бер зарар китерәчәге яки кешеләрнең шикләнеп сиңа иярмәячәкләре кебек уйларга бирелеп) Курыкма! Һичшиксез, син өстен чыгачаксың».**

«Та һа», 20:67-68

Муса галәйһиссәлам: «Кешеләр могҗизаны күргәч, аның мөмкинлекләрен арттырып кабул итәрләр һәм иманга килмәсләр», – дип курка.

Аллаһы Тәгалә аның бу сүзләренә каршы Муса галәйһиссәламгә болай дип әйтә:

**«(Алар күрсәткән моның кадәр бауларны, арканнарны һәм шуышкан елан шикелле күренгән терекөмешле буялган әйберләрне һич игътибарга алма!) Уң кулындагыны (кечкенә булып күренгән таягыңны җиргә) ташла, алар ясаган нәрсәләрнең бөтенесен (Минем кодрәтем белән) йотып бетерсен. Алар ясаган ул әйберләр, һичшиксез, сихерче хәйләсе. Сихерче исә кая барса (һәм ни кылса) да, уңышка ирешмәс».**

«Та һа», 20:69

Муса галәйһиссәламнең җиргә ташланган таягы исә бик зур еланга әйләнә, ул аждаһа сихерчеләрнең җиргә ташлаган бар әйберләрен дә кабып йота. Тузан суыргыч келәмдәге бар тузанны суырып бетергән кебек, ярыш оештырылган кыр да бер мизгелдә бар сихердән арынып кала.

*Дәвамы киләсе санда*

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы мөфтие**

# Шәгъбан ае

Шәгъбан ае – мөбарәк айлардан санала. Ул һәр мөселман өчен изге булган Рамазан аеннан алда килә торган, фазыйләтле һәм шәрәфле, Аллаһы Тәгаләнең бүләгенә лаек була торган ай. Бу ай күп кенә мөһим вакыйгаларга да бай. Ислам тарихында иң мөһимнәренең берсе – «Тахвили кыйбла», ягъни кыйбланың үзгәртелүе нәкъ менә шушы шәгъбан аенда булганы турында да әйтеп үтәргә кирәк.

Шәгъбан аеның унбишенче көнендә, Мәдинәи Мөнәүвәрәнең «Бәни Сәләмә» мәчетендә Расүлуллаһ галәйһиссәлам өйлә намазы фарызының ике рәкәгатен укып торган вакытында вәхи иңгән: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намазда торган хәлендә кирегә Кәгъбә тарафына борылган. Бу халәтне күргән сәхабәләр дә аңа ияреп намазны дәвам иттергәннәр.

Расүлебез галәйһиссәлам: «Раҗәб ае – Аллаһы Тәгаләнеке, шәгъбан – минем ай, Рамазан ае – минем өммәтемнеке. Шәгъбан – гөнаһларга кәффарәт була торган ай, ә Рамазан ае – гөнаһлардан пакьләнә торган ай», – дип әйткән.

Бу айда шәфкать капкалары ачыла, һәрнәрсәнең дә бәрәкәте арта, безнең көндәлек тормышыбызда белеп яки белмичә ясала торган хаталар кимиячәк, гөнаһлар гафу ителә. Шулай ук Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә күп салаватлар әйтелә торган ай.

Шулай итеп, мөселманнарга тәүбәгә килеп, гөнаһлардан арынып һәм дә инде гафиллектән уянып, Рамазан аена хәзерләнү кирәк. Бу ай – Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең ае булу сәбәпле, Аллаһы Тәгаләдән белеп һәм белмичә эшләгән гөнаһлар өчен гафу-истигъфар сорап, Аңа якынлашу хәерле гамәлләрдән санала.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Синең Раббың теләгәнен бар кыла һәм (теләгәнен) сайлый. Аларда исә сайлау (хакы) юк. Аллаһы (һәртөрле кимчелекләрдән) пакь! Ул алар Аңа ширек кушкан нәрсәләрдән өстен».**

«Касас / Хикәя», 28:68

Раббыбыз Үзенең коллары өчен бары тик иң изге, яхшы, файдалы һәм гүзәл нигъмәтләрне генә сайлап алып бирә.

Ул һәрнәрсәдән дә дүртне сайлап алып, соңыннан шулар арасыннан берсен якынайтып, дәрәҗәсен күтәрә. Мәсәлән: фәрештәләрдән – Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Газраилне сайлап алып, Җәбраил галәйһиссәламне иң олугы итеп куя. Мөхәммәд галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек вазифасын үтәү вакыты җиткәч, Үз сүзләрен җиткерер өчен Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештәне арадашчы итеп сайлый. Шуннан соң Җәбраил галәйһиссәлам аять-аять егерме өч ел дәверендә Раббыбыз сүзләрен җиткереп тора.

Көннәрдән – Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме, Гарәфә көне һәм Гашурә көннәрен сайлап ала. Шулардан Гарәфә көне мөселманнар өчен бөегрәк һәм хәерлерәк булып санала.

Айларга килгәндә, алар да дүртәү: раҗәб, шәгъбан, Рамазан һәм мөхәррам. Аллаһы Тәгалә барысына да караганда шәгъбанны аерып алып, аны Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең ае итеп билгеләде. Шулай итеп Мөхәммәд галәйһиссәлам башка пәйгамбәрләргә караганда өстен булган кебек, шәгъбан ае да башка айларга караганда өстенрәк.

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә: «Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең хәдисендә болай дип әйтә: «Раҗәб аеның өстенлеге: Коръәни Кәримнең башка китапларга карата булган өстенлеге кебек. Шәгъбанның башка айлардан өстенлеге: минем җир өстенә килеп киткән барлык пәйгамбәрләр белән чагыштыргандагы өстенлегем кебек. Ә Рамазан аеның өстенлеге: Аллаһы Тәгаләнең мәхлукатларына карата булган өстенлеге кебек».

Шәгъбан ае бәрәкәтле ай. Бу айда Аллаһы Тәгалә нигъмәт капкаларын ача һәм колларына чиксез рәхмәтен ирештерә. Шуңа күрә дә бу айда ваемсызлыктан аерылып, вакытны күбрәк догада һәм зикердә үткәрү хәерле булыр.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам шәгъбан аенда бик күп ураза тоткан. Бервакыт бер сәхабә Аллаһының Илчесе галәйһиссәламнән: «Әй Пәйгамбәр, мин синең шәгъбаннан да күбрәк ураза тотканыңны күргәнем юк (Рамазан ае уразасы – фарыз, ә шәгъбан аенда ураза фарыз түгел һәм ул һәркемнең үз ихтыярында, бу очракта Рамазаннан кала башка айлар да күздә тотыла). Моның сәбәбе нәрсәдә?» – дип сораган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Бу айда барлык гамәлләр дә Аллаһының хозурына ирешә. Мин гамәлләремнең үзем уразалы вакытта ашуын телим», – дип җавап биргән.



Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Шәгъбан аена шундый исемнең бирелү сәбәбе шундадыр: бу вакытта ураза тотучыларга Раббылары тарафыннан күп изгелек була, чөнки тоткан уразаның әҗере агач ботаклары кебек тармаклана, ишәя. Бу инде җәннәткә керергә сәбәпче була», – дип безгә бу айның фазыйләтен аңлатып биргән.

Гайшә радыяллаһу ганһә: «Мин Расүлуллаһның Рамазан аеннан кала, башка айларда тулысы белән ураза тотканын, һәм башка айларга караганда, шәгъбан аеннан да күбрәк ураза тотканын күрмәдем».

Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә: «Расүлуллаһ Рамазаннан тыш, бер айда да шәгъбан аенда тоткан кадәр ураза тотмады», – дип әйткән.

Тагын хәдистә әйтелә: «Рамазан аеның уразасыннан соң иң фазыйләтлесе, Рамазанга хөрмәт йөзеннән, шәгъбан аенда тоткан ураза. Иң фазыйләтле садака – Рамазан аенда бирелгәне».

Шәгъбан ае бик тә кыйммәтле һәм дәрәҗәле ай. Безнең сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең ае булу сәбәпле, мөселман бәндәсенең теле һәм яшәгән һәр көне салаватлар белән зиннәтләнергә тиеш. Салаватлар әйтү, ул беренчедән – Аллаһы Раббыбызның әмерен үтәү булса, икенчедән – Пәйгамбәребез галәйһиссәлам каршында булган хакны үтәү була. Салават ул, Аллаһыдан – рәхмәт, фәрештәләрдән – истигъфар һәм мөэминнәрдән – дога, дигән сүз. Салаватның иң кыскасы: Әллааһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәд.

Йә Раббым, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дөньяда ихтирамга лаек, исеме бөек һәм мәшһүр. Гүзәл динебезне дәвамлы, Ахирәттә савапларны чиксез, Пәйгамбәребез галәйһиссәләмне шәфәгатьче итеп җәннәт бакчаларында бергә-бергә җыелып, бергә-бергә күрешүләр насыйп ит.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үзенең хәдисендә: «Кыямәт көнендә, бер җирдә дә күләгә булмаган вакытта, өч төркем кеше Гареш күләгәсе астында булырлар. Берләре – минем өммәтемә авыр вакытта ярдәм кулы сузучылар, икенчеләре – минем сөннәтемне үтәүчеләр, ә өченчеләре – миңа күп итеп салават әйтүчеләр», – дип әйткән. Шулай ук тагын бер хәдисендә: «Кем миңа җомга көнне йөз тапкыр салават әйтсә, Аллаһы Тәгалә ул кешенең йөз ихтыяҗын, кайгы-хәсрәтен юкка чыгарыр. Утызын дөньяда, җитмешен Ахирәттә. Исән вакытымда миңа салават әйтүчеләрне белгән кебек, үлемемнән соң да мин аларны белермен», – дип әйткән.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһедән китерелә: «Расүлуллаһка салават әйтү – су утны сүндергән кебек, гөнаһларны бетерә. Аңа сәлам бирү – колны азат итүдән дә саваплырак. Аны әти-әниеңнән, балаларыңнан да күбрәк ярату – Аллаһы Тәгалә юлында җиһад кылганнан да өстенрәк».

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам күп кенә хәдисләрендә салават турында мәгълүмат бирә. «Кем миңа салават әйтә, мин аңарга Кыямәт көнендә шәфәгатьче булырмын».

«Аллаһы Тәгалә әмере буенча бер фәрештә Кыямәт көне җиткәнчегә кадәр минем каберем янында торыр. Әгәр минем өммәтемнән берәү салават укыса, «Фәлән улы фәлән яки фәлән кызы фәлән сиңа салават укыды», – дип әйтер. Бер салаватка Аллаһы Тәгалә ун әҗер бирер, кем дә кем күп тапкырлар укыса, әҗере дә чиксез булыр».

Шушы мөбарәк шәгъбан аен бушка түгел, ә булдыра алганча гыйбадәттә үткәрсәк файдасы чиксез булыр. Шәгъбан ае изге Рамазан аена исән-имин керергә сәбәпче булса иде. Әзерлекне алдан ук башларга кирәк. Галимнәр болай дип әйткәннәр: «Сәхабәләр изге айга алты ай кала әзерләнә башлаганнар. Аллаһыдан: «И, Раббым, шәгъбан аен изгелектә уздырып, Рамазан айларын күрергә насыйп итсәң иде. Гыйбадәт кылудан мәхрүм кылмасаң, тәүбәләребезне кабул итсәң иде, дип сораганнар». Сәхабәләр безгә үрнәк булып торалар.

■ **«Хозур» редакциясе**

# Хатын-кызга кагылу тәһарәтне бозамы?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм, хәзрәт! Мин шәфигыйлар җирлегендә хәнәфи мәдрәсәсендә укыдым. Шәфигый җирлегендә ир белән хатынның кочаклашуы, үбешүе яисә берберләренә кагылуы нәтиҗәсендә аларның икесенең дә тәһарәте бозыла дигән фикер яши. Берәүләр «Кудури» китабы буенча гамәл кыла, икенчеләре тәннең икенче тәнгә тиюеннән тәһарәт бозыла дип санаучы шәфигыйлар белән каршылыкка кермәс өчен тырыша. Бу очракта аларга нинди дәлил китерергә?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Бу очракта бер киңәш бар: төгәл белмәгән мәсьәләләргә кермәскә. Ә фикһ буенча ышанычлы дөрес гыйлемнәргә бары остаз белән мәзһәбнең дәрәҗәле китапларын өйрәнеп кенә ирешеп була.

Хәнәфи мәзһәбе буенча ирнең тәне хатынының тәненә тиеп китүдән тәһарәт бозылмый. Әйе, әгәр дә шәфигыйлар белән каршылыктан чыгу теләге бар икән, тәһарәтне яңартырга мөмкин, әмма ул бозылган өчен түгел, ә тәһарәтне яңарту бу очракта, имам Әш-Шурунбуләли «Нур әл-идах» хезмәтендә язганча, теләк буенча булганы (мәндүб, мөстәхәб) өчен. Тәһарәт мәндүб булган очракларны санаганда, имам Әш-Шурунбуләли шәфигый мәзһәбе буенча хатын-кызга кагылулардан тәһарәт бозылу очрагын да кертә. Хәнәфиләрдә исә «мүбәшарә фәһишә», ягъни ирләрнең җенес әгъзасы каршылыксыз, шәрә килеш хатын-кызның җенес әгъзасына тию генә тәһарәтне боза, дип әйтелә. Бу очракта җенси якынлык турында сүз бармый, ә шәһвәтлек турында гына сүз бара («Нур әл-идах»).

Ә үбешүләргә килгәндә, сак булу сорала, чөнки бу очракта хисләнүдән мәзи чыгу ихтималы бар, ә мәзи чыгу тәһарәтне боза һәм нәҗес санала. «Бәдәиг әссәнаи» китабы авторы мәзигә түбәндәге билгеләмәне бирә:

وَالْمَذْيُ رَقِيقٌ يَضْرِبُ إلَى الْبَيَاضِ يَخْرُجُ عِنْدَ مُلَاعَبَةِ الرَّجُلِ أَهْلَهُ (بدائع الصنائع في ترتيب الشرائع، ج1 ص37، دار الكتب العلمية)

«Мәзи – назлаулар вакытында чыга торган куе булмаган ак төстәге сыеклык». Ирдән мондый сыеклык чыкса, тәһарәт бозылды дигән сүз, сыеклыкны тәннән яисә киемнән юып алырга кирәк. Әгәр назлар вакытында ир-атның берниндн сыеклыгы да чыкмаса, тәһарәт бозылмаган була.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

# Келәм чистарту

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Келәмнәргә нәҗес (сидек, косык) тисә, ул урынны өч тапкыр юеш чүпрәк белән сөртү җитәме?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Келәмне өч тапкыр юеш чүпрәк белән сөртү генә җитми. Нәҗеснең төренә карап, келәм чистартуның ике варианты бар:

1) Әгәр нәҗес кибеп, беленерлек эз калдырмаса (мәсәлән, сидек). Келәм калын булып, аны сыгу мөмкинлеге булмаса яисә келәм идәнгә беркетелгән булса, сидек тигән урынга су бөркеп, аны чүпрәк белән сеңдереп, келәмне киптерү кирәк. Бу гамәлне өч тапкыр эшләү тиешле. Әгәр келәм юка булса, аны өч тапкыр юып, өч тапкыр сыгу җитә. «Әл-Фәтва Әл-Һиндия» китабында болай диелә:

وما لا ينعصر يطهر بالغسل ثلاث مرات والتجفيف في كل مرة

«Сыгып булмый торган әйберне өч тапкыр юып, өч тапкыр киптереп чистарталар».

2) Әгәр нәҗес кибеп, аның эзе калса (мәсәлән, кан). Бу очракта таплы урынга тап бетәрлек кадәр су салырга кирәк. Әгәр беренче тапкырдан бетсә, бер тапкыр да җитә; әгәр бетмәсә, беткәнче су салу кирәк. Гадәти ышкып юганнан соң тап бетмәсә, бу урын чистарган санала. Махсус чистарткычлар куллануның кирәге юк, бары теләк буенча гына, чөнки кан табының эзе бер дә матур түгел. «Әл-Фәтва Әл-Һиндия» китабында болай диелә:

وإزالتها إن كانت مرئية بإزالة عينها وأثرها إن كانت شيئا يزول أثره ولا يعتبر فيه العدد

فلو زالت عينها بمرة اكتفى بها ولو لم تزل بثلاثة تغسل إلى أن تزول

وإن كانت شيئا لا يزول أثره إلا بمشقة بأن يحتاج في إزالته إلى شيء آخر سوى الماء كالصابون لا يكلف بإزالته

وكذا لا يكلف بالماء المغلي بالنار

«Күзгә күренеп торган нәҗес – нәҗеснең үзен яисә аның эзен бетерү белән (әгәр бетереп булса) чистартыла. Кулланылган су күләме әһәмиятле түгел. Нәҗес бер тапкырдан бетсә, шул да җитә. Өч тапкырдан да бетмәсә, тап беткәнче юу кирәк. Әгәр тапны бетерү өчен махсус чистарткычлар кирәк икән, аларны куллануның кирәге юк, ягъни махсус каты ышку кирәкми. Шулай ук суны җылыту да кирәк түгел».

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

# Instagramда бәйгеләр уздыру

**Сорау. Әссәләмү галәйкүм! Instagramда бәйгеләр уздыру ешаеп китте. Дусларыңны күрсәтеп язма астында комментарийлар калдыру һәм лайклар куйган өчен ниндидер бүләк уйнату рөхсәт ителгәнме? Бүләк өчен генә болай уйнау ялганда катнашу булмыймы?**

**Җавап.** Вә галәйкүм әссәләм! Ислам финанс учреждениеләренең аудит һәм бухгалтерия хисабы оешмасының «Бәйгеләр һәм бүләкләр» дип исемләнгән 55 нче номерлы шәригать стандартында болай диелә: «Маркетинг бүләге – тегеяки бу товарны, хезмәтне алга үстерү яисә билгеле бер сәүдә урыннарына инвесторларны җәлеп итүгә юнәлдерү өчен махсус уйлап табылган бүләк. Компания, үз эшләнмәләрен яисә үз хезмәтләрен сатып алсыннар өчен, бүләк уйнатырга, баллар системасын кулланырга яисә бүләкне гади генә тапшырырга мөмкин.



Товарны, хезмәтне сатып алу шартын куймыйча, бүләк уйнату рөхсәт ителгән. Сатып алырга тәкъдим ителә торган товар яисә хезмәт бүләк уйнатуның шарты булган очракта, шәригать күзлегеннән рөхсәт ителгән булырга тиеш.»

Димәк, әгәр дә товарны сатып алу шарт итеп куелмаган булса, Instagramда бәйгеләр уздырып бүләк уйнату дөрес гамәл. Бүләкнең шәригать законнарына туры килүе дә шарт булып тора.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

# Товарны сатып алганнан соң бүләк уйнату шәригатькә туры киләме?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Ислам атрибутикасы кибетләренең товар алучылар арасында гомергә юллама уйнатулары шәригатькә туры киләме?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Ислам финанс учреждениеләренең аудит һәм бухгалтерия хисабы оешмасының «Бәйгеләр һәм бүләкләр» дип исемләнгән 55 нче номерлы шәригать стандартында болай диелә: «Маркетинг бүләге – тегеяки бу товарны, хезмәтне алга үстерү яисә билгеле бер сәүдә урыннарына инвесторларны җәлеп итүгә юнәлдерү өчен махсус уйлап табылган бүләк. Компания, үз эшләнмәләрен яисә үз хезмәтләрен сатып алсыннар өчен, бүләк уйнатырга, баллар системасын кулланырга яисә бүләкне болай гына да тапшырырга мөмкин.

Товарны, хезмәтне сатып алу шартын куймыйча, бүләк уйнату рөхсәт ителгән. Сатып алырга тәкъдим ителә торган товар яисә хезмәт бүләк уйнатуның шарты булган очракта, шәригать күзлегеннән рөхсәт ителгән булырга тиеш.»

Бүләк уйнатканда, товар сатып алу шарт булып торган очракта, түбәндәгеләргә игътибар итү тиешле. Товарның бәясен арттыру ярамый, ягъни ул гадәти көннәрдәге бәядән кыйммәтрәк булырга тиеш түгел. Сатып алучының максаты бүләк оту түгел, ә товар яисә хезмәтне сатып алу булырга тиеш. Бүләк оту мөмкинлеге барлык катнашучылар өчен дә бердәй булырга тиеш. Бүләк уйнатканда турыдан-туры яки читләтеп комиссия алу яисә өстәмә түләү кертү тыелган.

Шушы шартлар үтәлгән очракта, товар сатып алу шарты белән бүләк уйнату шәригать буенча рөхсәт ителгән.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

**■ Булат Мөбәраков,**
**ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе**

# Бәраәт кичәсе

Без раҗәб белән Рамазан ае уртасында булган мөбарәк ай – шәгъбан аена аяк бастык. Бу айда мәртәбәле Бәраәт кичәсе бар.

Аны «Ләйләтел-Бәраәт» дип атыйлар. «Ләйләтел-Бәраәт»нең мәгънәсе «пакьләнү», «бурычтан вә җәзадан котылу» дип аңлатыла. Гарәп телендә әлеге мөбарәк кичәне «ләйләтел-мөбарәкә», «ләйләтел-гуфран», «ләйләтел-бәра», «тәкфир» дип тә йөртәләр. Моның хакында элеккеге китаплардан укып белергә, шәех һәм хәзрәтләрнең сүзләреннән ишетергә мөмкин. Гарәпләрнең гадәте буенча бик кыйммәтле әйберләрне генә төрле күркәм исемнәр белән бизәп әйтә торган иделәр. Аларның мондый мәкале билгеле: «Күп исемле була торган зат – шәрәфле, дәрәҗәле була».

Әлеге айның мөселманнар тарихында фазыйләтләре бик күп, хәдистә болай дип әйтелә: Имам Әт-Тирмизи Гайшә радыяллаһу ганһәнең әлеге сүзләрен риваять итә: «Бер кичне Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне югалтып, аны эзләргә чыктым, ул Бәкыйгъ дигән зиратта иде. Аллаһы Илчесенең янына килгәч, ул миңа: «Йә, Гайшә, әллә син Аллаһы сиңа һәм Үзенең пәйгамбәренә зарар китерер, дип курыктыңмы», – диде. Мин: «Син башка хатыннарың янына киткәнсең, дип уйладым», – дип әйттем. Шуннан соң пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый сүзләр әйтте: «Дөреслектә шәгъбан аеның уртасындагы кичтә Аллаһы Тәгалә Бәни Киләб кабиләсе сарыкларының йоннары санынча кешеләрне җәһәннәмнән азат итәр».

## Бәраәт кичендә күбрәк гыйбадәт кылыгыз

Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгында Гали бине Әбү Талибның әлеге сүзләре риваять ителә: «Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Шәгъбан аеның уртасындагы кичне – Бәраәт кичәсен гыйбадәт, намаз белән уздырыгыз. Көндезен ураза тотыгыз, чөнки ул кичне Аллаһы Тәгалә кояш баеганчыга кадәр дөнья галәменә рәхмәт иңдерә һәм болай дип әйтер: «Гафу сораучы юкмы – аны гафу итәрмен, ризык сораучы юкмы – аны ризыкландырырмын, кайгылы вә авыру кеше юкмы – аңа шифа бирермен. Моннан башка нинди теләкләре булса, сорасыннар – бирермен. Һәм бу хәл таң атканчыга хәтле дәвам итәр».

Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый нәсыйхәт бирә: «Бәраәт сезнең өчен зур форсаттыр, бик күп мөмкинлекләр бирә торган изге кичтер. Кадер кичәсе Бәраәт кичәсеннән зуррак булса да, кайчан булганы төгәл билгеле түгел. Шуңа күрә Бәраәт кичендә күбрәк гыйбадәт кылыгыз».

# Бәраәт – мөбарәк кичә



Бүгенге көндә кайбер кешеләр, бу бидгать гамәл, дип куркыныч сүзләр әйтәләр. Бу рәвешле фикер йөртүче сахих хәдисләргә каршы чыга, хакыйкатьне инкяр итә. Мондый сүзләр әйтүчеләр белә торып Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә яла яккан кебек була. Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам: «Кем белә торып миңа яла яга, шуның урыны җәһәннәмдә булсын», – дип әйткән. Имам Әхмәдтән 40 мең хәдисләр тупланган җыентыгы турында: «Сезнең китабыгызда зәгыйфь хәдисләр бармы?» – дип сорадылар. Ул: «Әйе бар, мин аларны махсус калдырдым, чөнки башка риваятьләрдә аларның сахихлыгын исбатлый торган хәдисләр килергә мөмкин», – дип әйтте.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

**«Без ул Коръәнне мөбарәк Кадер кичәсендә иңдердек, Без Коръән белән имансызларны «куркытучы» булдык. Ул Кадер кичәсендә киләсе елга хәтле булачак эшләр хөкем ителер, ягъни тумак, үлмәк, ризык вә дөньядагы башка булачак вакыйгалар тәгаен ителер. Һәр әмер хикмәт буенча Безнең хозурыбызда хасил булган хәлдә, Без ул көндә мөэминнәргә фәрештәләр җибәрер булдык».**

«Духан / Төтен», 44:3-5

Мөбарәк кичләрнең берсе – Бәраәт кичендә Аллаһының рәхмәте белән кыйбла юнәлеше Бәйт Әл-Мәкъдистән Кәгъбәтуллага күчкән.

Шушы айда Расүлебез галәйһиссәлам күпләп ураза тотты. Ул бу көндә күп кешенең вакытларын гафиллектә үткәрүен әйтә иде. Пәйгамбәребез: «Раҗәб белән Рамазан арасындагы айда кешенең кылган гамәлләре Аллаһы хозурына күтәрелә. Бу вакытта уразалы хәлдә булырга телим», – дип әйткән, үзе шәүвәл аенда ураза тота торган булган. Ул: «Безнең гамәлләребез көненә ике мәртәбә: иртә һәм кич, атнасына ике тапкыр: дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе һәм елга бер тапкыр: шәгъбан аенда Аллаһы хозурына күтәрелә», – дигән.

Гади генә бер мисалга күз салыйк: әйтик, бер патша, миңа бурычлары булган кешеләр билгеле бер вакыт эчендә гафу сорасалар, аларны гафу итәрмен, дип әйтсә, нишләрләр иде икән? Бу чагыштырыр өчен генә әйтелде. Аллаһы Раббыбыз бу мисаллардан күпкә өстен.

## Бу кичтә нинди гамәлләр кылырга?

Бәраәт кичәсендә 12 рәкәгать нәфел намазы үтәлә. Һәр рәкәгатьтә бер тапкыр «Фәтихә», өч тапкыр «Ихлас» сүрәләре укыла.

Намаздан соң түбәндәге догаларны укырга мөмкин:

1. Ләә иләәһә илләллаһ вәхдәһү ләә шәриикә ләһ. Ләһүл мүлку вә ләһүл хәмду, вә һүә галәә күлли шәй иң кадиир. 2. Әстәгъфируллаһүл газыйммә вә әтүбү иләйһи. 3. Аллаһуммә салли вә сәллим вә бәәрик галәә сәийдинә Мөхәммәдин вә галәә әәли Мөхәммәд.

Бу кичтә Коръәни Кәрим укып, дога кылу хуп күренә, гореф-гадәтебез буенча өч мәртәбә «Йәсин» сүрәсен уку хуплана. Шушы гадәт бүгенгә хәтле Мисырда да сакланып калган. Бәраәт көнен уразада үткәрү киңәш ителә.

«Бәраәт» догасы:

Мәгънәсе: Йә Аллаһым, әгәр мине бәхетсез итеп, исемемне бәхетсезләр дәфтәренә язган булсаң, аны сөртеп юк итсәң иде һәм бәхетлеләр дәфтәренә язсаң иде. Әгәр мине бәхетлеләрдән итеп, исемемне бәхетлеләр дәфтәренә язган булсаң, әлеге язуны беркайчан да сөртелми торган ит. Чынлыкта, Син Коръәни Кәримеңдә: «Аллаһы Тәгалә нәрсәне теләсә, Ләүһүл-Мәхфүздән шуны сөртер, юк итәр, теләгәнен исә беркетер, сөртелмәс итәр», – дип әйтәсең.

Аллаһы Раббым шул күркәм гадәтләрне саклап, бер-беребезгә хәер догада, тынычлык иминлектә яшәргә, бозык фикерләрдән вә бозык эшләрдән сакланырга насыйп итсен.

Фөдәйл бине Гыяд: «Әгәр дә минем кабул булына торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылар идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә дәүләт җитәкчебезнең саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, житеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен насыйп ит!

■ **Сәхифәне ТР МДНнең Дәгъват бүлеге җитәкчесе Габбас хәзрәт Кадыров әзерләде**

# Казанда Рамазан алдыннан «Чиста мәчет» акциясе уза

**15 нче март көнне Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте волонтёрлары «Чиста мәчет» акциясе кысаларында изге Рамазан ае башланганчы Залесный бистәсендә урнашкан «Мәүлид» мәчетендә өмә үткәрде. Әлеге изге эштә 15 кеше катнашты.**

Кызлар бөтен тәрәзәләрне, стеналарны, идәннәрне юды, тузан сөртте, ә балалар аларга чиләк белән су ташыды, чүп-чар тутырылган капчыкларны чыгарырга булышты. Егетләр мәчет әйләнә-тирәсен тәртипкә китерде. Төш вакытына эш тәгәлләнде. Аннары, намаз укыганнан соң, мәчет имам-хатыйбы Радик хәзрәт Фазлиев яшьләргә вәгазь укыды, шулай ук мәчет төзелү тарихын сөйләде. Очрашу ахырында чәй мәҗлесе узды.


Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: әлеге акция кысаларында яз башыннан мөселман яшьләр активы вәкилләре Казанның «Рамазан», «Мәдинә» һәм «Гаилә» мәчетләрендә өмә үткәрде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Миңа өммәтташларем өчен әзерләнгән әҗер-саваплар күрсәтелде, алар арасында хәтта кеше мәчеттән алып чыккан тузан бөртеге өчен дә савап бар иде».

Аллаһы Тәгалә изге гамәлләрегезне кабул итсен!

Исегезгә төшерәбез: «Чиста мәчет» акциясе 2017 елдан бирле Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль үсеш бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла. Шулвакыт эчендә анда катнашу өчен яшьләр арасыннан ике йөзләп мөселман-волонтёр җәлеп ителде, алар Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен Татарстан мәчетләрендә өмә үткәрде.

■ **dumrt.ru сайтыннан**



# Казанда мөслимәләр өчен «Яшь килен» проектының икенче сезоны башланды





12 нче март көнне Казанда мөслимәләр өчен «Яшь килен» проектының икенче сезоны башланды. Кич белән Галиев мәчетендә беренче очрашу – проектта катнашучы кызлар белән танышу кичәсе узды. Беренче утырышка кырыкка якын мөслимә җыелды. ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль бүлек җитәкчесе Айгөл ханым Биктимерова һәм проектның кураторлары алар белән беренче әңгәмә уздырды.

Шунысы игътибарга лаек: проектның яңа сезоны кызларны яңа формат белән сөендерде. Әгәр сез башка шәһәрдән булсагыз, хәзер «Яшь килен» проектында онлайн режимда да катнашырга мөмкин. Шулай итеп, Казанда яшәүче оффлайн катнашучылардан тыш, яңа сезонда Мәскәү, Чиләбе, Кемерово, Уфа, Екатеринбург, Нижневартовск, Чаллы шәһәрләреннән, Балтач, Алексеевск, Теләче, Чистай, Азнакай районнарыннан барлыгы алтмыштан артык кыз катнашачак.

Ике ай дәвамында кызлар өчен никах, әни булу серләре, психология, хуҗалык эшләрен алып бару темаларына багышланган 7 оффлайн-очрашу һәм никах килешүе, физиология, аерылышу һ.б. темаларга багышланган 6 онлайн-дәрес узачак. Сәламләү сүзләреннән соң һәм катнашучыга «Яшь килен» көндәлекләрен бүләк иттеләр. Әлеге дәфтәрләр ярдәмендә кызлар өй эшләрен башкарачак һәм даими файдалы эшләр трекерын теркәп барачак.

«Яшь килен» проектының киләсе очрашуы 19 нчы мартта узачак, анда катнашучыларга тормыш иптәшен дөрес сайлау турында сөйләячәкләр.

«Яшь килен» проекты мөселман яшьләре арасында гаилә кыйммәтләрен ныгыту максатыннан гамәлгә ашырыла, шәригать һәм татар милли гореф-гадәтләр күзлегеннән чыгып никах темасының төрле мәсьәләләренә багышлана. Очрашулар һәм видео-дәресләрдә булачак һәм хәзерге яшь киленнәргә милли традицияләр – бәби чәе, бишек җыры, кыз озату һ.б., никахның дини һәм хокукый яклары, ир-атның һәм хатын-кызның вазифалары һәм хокуклары, мәһәр һәм никах килешүе, хатын-кыз һәм ир-ат психологиясе кебек мәсьәләләр турында сөйләнәчәк. Моннан тыш, мөслимәләр милли ашлар әзерләргә, бала карарга, кунакларны каршыларга өйрәнә алачак. Спикерлар сыйфатында психологлар, юристлар, табиблар, галимнәр чыгыш ясаячак. Курслар һәр атна саен Галиев мәчетендә 18:30 вакытта уза. Йомгаклау дәресе 30 нчы апрель көнне ифтар форматында булачак. Шунысы да мөһим: проектта катнашучыларның яше чикләнмәгән.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Коронавирус таралуга бәйле рәвештә, Нәзарәт үз тәкъдимнәрен җиткерә

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, коронавирус таралуга бәйле рәвештә, түбәндәге тәкъдимнәргә буйсынырга киңәш итә:

1. Вирус йоктыру ихтималы югары булган илләргә сәфәр кылудан тыелып торырга. Имам Бохари җыентыгында килгән хәдистә түбәндәгеләр әйтелә:

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән тапшырыла, ул болай дигән:

«Әгәр берәр җирдә ваба (чума) таралуы турында ишетсәгез – ул урынга бармагыз; әгәр ваба авыруы хәзерге вакытта сезнең җирлектә таралыш алса, яшәгән урыныгызны ташлап китмәгез» (5728).

Шулай итеп, Пәйгамбәребез саллләлаһу галәйһи вә сәлләм 1400 ел элек үк эпидемияләр таралганда үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә нигез салган.

2. Чисталыкка һәм гигиенага зур игътибар бирергә. «Сахих» Мөслим хәдисләр җыентыгында түбәндәге хәдис бар: Әбү Мәлик Әл-Әшгари радыяллаһу ганһе тапшырганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

«Чисталык (гигиена) – иманның яртысы» (223).

3. Төчкергәндә һәм йөткергәндә гигиена кагыйдәләрен үтәргә. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә түбәндәгеләр әйтелә:

«Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм төчкергәндә авызын кулы яки тукыма кисәге белән каплаган» (Тирмизи/2745).

4. Даими рәвештә бүлмәне дезинфекцияләргә, чөнки вирус һава белән тарала. Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

«Өегезне ладан (любан), мирра (мурр) һәм тимьян (хуш ис килә торган үсемлек) белән төтәсләгез, ягъни яндырып исен чыгарыгыз» (Әл-Маталиб Әл-Алия/2448).

Барлык дезинфекция ясау чараларын куллану рөхсәт ителә.

5. Якыннарыбыз: әти-әниләребез (бигрәк тә алар өлкән яшьтә булса) һәм балалар өчен безгә йөкләнгән җаваплылык турында онытмаска.

Без туганнарыбызга, якын кардәшләребезгә профилактика чаралары турында сөйләргә тиешбез.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

«Сезнең һәрберегез көтүче, һәм һәркайсыгыз үзенең көтүе өчен җаваплы» (Бохари).

6. Аллаһы Тәгаләдән дөньяның барлык мөселманнары өчен гөнаһларның гафу ителүен һәм иминлек насыйп булуын сорап дога кылырга.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дигән:

«Һичшиксез, алар (кешеләр) үз нәфесләрендә булганны алмаштырмый торып, Аллаһы кешеләрдә булганны алмаштырмый» (Әр-Рагъд/11)

7. Әбү Давыд хәдисләр җыентыгында килгән хәдистән доганы еш укырга:

«Раббым, мин Синнән махау (проказа) авыруыннан, акылсызлыктан, лепра (хроник инфекцион авыру) чиреннән һәм начар авырулардан саклавыңны сорыйм» (1554).

8. Әгәр кеше хәлсезләнсә, кичекмәстән табибларга мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Аллаһы Тәгалә «Нәхел» сүрәсенең 43 нче аятендә болай дип әйтә:

**«Без синнән алда да (кешеләргә пәйгамбәр итеп) ирләр җибәргән идек, шуларга вәхи иттек. Әгәр сез белмәсәгез, зикер ияләреннән сорагыз».**

Шулай ук, хәлсезлек хисен тойган кеше башка кешеләрне вирус йоктырудан сакланырга тиеш. Шуңа күрә авыру кешегә халык күпләп җыела торган урыннарга барудан тыелып торырга кирәк.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Син – ул синең ашый торган ризыгың

Адәм баласы булганның кадерен белмәүче зат. Игътибар итегез әле, бездә нәрсә дә булса җитәрлек күләмдә икән, безнең аңа бөтенләй дә кадерхөрмәтебез югала; ә менә ул нигъмәт, байлык кими башласа, хафалана башлыйбыз. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: биш нәрсә килгәнче, икенче бишнең кадерен бел, дигән. Шуларның берсе сәламәтлек. Сәламәт, көчле кеше, сүз бигрәк тә яшьләр турында бара, гомер буе шушы халәттә яшәрмен, дип уйлап ялгыша. Әмма бу фани дөньяда бернәрсә дә мәңгелек түгел. Күпмедер вакыттан соң сәламәтлек какшый башлый һәм кеше кайчандыр үзенә тиешле игътибар бирмәгәненә, әйтелгән киңәшләргә колак салмаганына үкенә.

Сәламәтлек – Аллаһы Тәгаләдән безгә әманәт итеп бирелгән. Һәм без, аңа битарафлык күрсәтеп, зур хата кылабыз. Кеше авырганда, сәламәтлеге белән проблемалар булганда, бу аның көнкүрешендә дә чагыла. Моңа кадәр булган гадәти гамәлләрне башкару аның өчен бер мәшәкатькә әйләнә. Болар, әлбәттә, аның гыйбадәтендә дә чагылыш тапмый калмый, чөнки билгеле бер кыенлыклар аркасында намаз уку, ураза тоту, әгәр мөмкинлеге булса, хаҗ сәфәрен кылу гамәлләрен башкаруы авырлаша. Әйе, сәламәтлеге какшаган кешенең аны яхшыртыр өчен бар тырышлыгын куюы, хәләл ысуллар белән дәваланып, Аллаһыдан дәва соравы хуплана торган күренеш. Әмма кешенең иң баштан ук: яшь, көчле вакытында сәламәтлегенә – кимеми торган байлык һәм кайгыртуга мохтаҗ түгел әйбер итеп караулары кызганыч.

Бервакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең абыйсы Габбас радыяллаһу ганһе аннан: «Йә, Аллаһының Илчесе! Миңа һәрдаим укып йөрерлек дога өйрәт», – дип әйткән. Расүлебез: «Йә, Аллаһым! Мин синнән гафу итүеңне, сәламәтлек һәм котылу сорыйм, дип әйт», – дигән (Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан).

Кайбер кеше сәламәтлекне саклауны төрлечә аңларга мөмкин. Берәүләр, минем начар гадәтләрем юк, һәрдаим табибка күренеп торам, авырганда дәваланам, дип әйтер. Әмма сәламәтлеккә Аллаһының нигъмәте итеп карау, аны әманәт дип белү моның белән генә чикләнәме икән?

Сәламәтлеккә әманәт буларак карау – аның кадерен белү һәм аңа карата динебез кушканча мөгамәләдә булу, дигән сүз. Шуларның берсе:

### Хәләл ризык ашау һәм дөрес туклану рәвешен сайлау

Коръәндә: **«И, кешеләр! Җирдә хәләл, (бөтен шик-шөбһәдән) пакь булганнардан ашагыз. Шәйтанның эзләреннән бармагыз, чөнки ул (шәйтан) – сезнең ап-ачык дошманыгыз»,** – дип әйтелгән.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:168

Дөньяви галимнәр дә хәләл ризыкның – сәламәт ризык булуын һәм кеше сәламәтлеге өчен файда гына китерүен исбатлады инде. Кеше динебез буенча тыелган ризык ашаган очракта, иртәме, соңмы сәламәтлеге өчен зарар ясаганын аңлаячак. Әмма хәләл ризыкның да чиге һәм хәләлнең дә үз тәртибе бар. Динебез буенча ризыкны хәл җыярлык һәм халәтебезне яхшыртырлык дәрәҗәдә генә кабул итәргә тиешбез. Пәйгамбәребез үзенең хәдисләрендә артыгын ашауның сәламәтлек өчен зур зыян салганлыгын ассызыклый: «Кеше тутыра торган иң начар чүлмәк – ул аның карыны. Адәм баласына көч туплар өчен берничә кисәк ризык җитә, ә инде күбрәк ашарга теләсә, ашказанының бер өлешен ризыкка, икенчесен суга, ә өченче өлешен сулыш алырга җиңел булырлык итеп бүлергә тиеш».

Галимнәр ашаган ризыкның тәнгә генә түгел, кешенең рухи халәтенә дә тәэсир ясаганын ачыклаган. Игътибар итсәк, бүген барлыкка килгән кайбер авыруларның сәбәбе – кешенең артык күп ашавы, җитмәсә зыянлы ризык кабул итүе. Бүгенге көндә күпләр диета белән сәламәтлекләрен яхшыртырга тырышкан вакытта, элек-электән әби-бабаларыбызның ашауга җитди караганнарын исәптә тотарга кирәк. Алар хәзерге заман кешесе кебек чамадан тыш тукланмаган. Дөрес, аларның андый мөмкинлекләре дә булмаган. Монысы инде икенчел мәсьәлә, әмма, ничек кенә булмасын, аз булса да, әмма сәламәт ризык ашаучы, сәламәтлек өчен зарарлы булганнарыннан тыелучы кеше күпкә дөрес яшәү рәвеше алып бара.

Расүлебез галәйһиссәлам: «Өммәтем өчен әлеге кимчелекләрдән куркам: ул – зур корсак, озакка сузылган йокы, ялкаулык һәм иман зәгыйфьлеге», – дип әйткән.

Мөселман галимнәре Ибне Сина: «Хасил булган барлык авыруларыбыз ризыкларыбыздан һәм эчемлекләребездән», Имам Газали: «Кешене һәлакәткә илтә торган иң зур сәбәп – аның корсак тутыруга һәвәслеге», – дип әйткәннәр.

Алар туклану мәсьәләсендә ике төп кагыйдәне аерып чыгара:

1. Ашыйсы килү теләге барлыкка килми торып, ризык кабул итмәү, ягъни кеше тамагы ачыккач кына ашарга утырырга тиеш.

2. Өстәл янынннан бераз ачлык хисе булган халәттә китү. (Бу, югарыда искә алынган: ашказанының бер өлешен һава өчен калдыр, дигән хәдискә таянып әйтелә). Һәм төп ризыклар ашау арасында тәгам кабул итмәү, ягъни ашап, өстәл яныннан купканнан соң икенче тапкыр ашарга утырганчы башка ризык капмау, һәрдаим ашап йөрүдән тыелу, дигән сүз.

Табиблар кеше ач торган вакытта организм үзендә тупланган төрле зарарлы матдәләрдән, токсиннардан азат ителә, дип әйтә. Шул рәвешле сәламәтлек өчен уразаның файдасы гаять зур роль уйнаганын аңлыйбыз.


Боларны белгән, кабул иткән кеше динебезнең хикмәткә корылганлыгын аңлар. Хакыйкый мөселман кешесе аның бәһасез кыйммәтләрен танып, тәртипләрен үтәп яшәп, ике дөнья бәхетенә ирешер.

■ **Айсылу Юлдашева**

# Япониянең беренче мөселман мәктәбе – «Исламия Мәктәбе»нең тарихы



1936 елның март ае.
«Исламия мәктәбе» укучылары өйлә намазын укый



«Исламия мәктәбе» бинасы (мәктәп бинасы күп кенә вакыт мәчет буларак кулланылган)

Идел-Урал татарларының революцион Рәсәйдән массакүләм рәвештә күченүләреннән соң, аларның бер төркеме Ерак Көнчыгышта (Маньчжурия) төпләнә. Чама белән 1919 елда Маньчжурия мөселманнарының бер өлеше Япониягә күченергә уйлый. Күпмедер вакыттан соң Япония башкаласы Токио качкын мөселманнарның төп үзәкләренең берсенә әйләнә.

Япония мөселман җәмәгатьчелеге темасы бик кызыклы. Токио мөселман җәмәгатьчелегенең күпчелеген татарлар тәшкил иткән. Һәм шулай ук берничә башкорт һәм уйгыр гаиләләре булган. Бу сорауга ачыклык кертү өчен, бүгенге көндә Төркиядә яшәүче, Токио җәмәгатьчелеге вәкиле Фазыл Агишның сүзләрен китерәбез: «Җәмәгатьчелекне татарларга һәм башкортларга аерып карау бик кыен. Без Токио җәмәгатьчелегендә Габделхәй Корбангали, Насыйбулла Хәлиуллиннарның башкорт икәнлекләрен белә идек, Җәлил Сабиҗан хакында йә типтәр, йә башкорт, дип әйтәләр иде. Хакыйкый күпчелекне Пенза татарлары тәшкил итә, әмма барысы да диярлек үзләрен Идел-Уралның төрки-татарлары яки мөселманнар дип атый. Шуңа күрә татарлар, башкортлар һәм хәтта уйгырларны да үзара аерып карамыйлар».

Ислам дине һәм татар мәдәнияте җәмәгатьчелекне берләштерүче төп фактор булып тора. Татарлар юкка гына Токионы сайламыйлар. Башкалада япониялe бик күп аристократлар, хәрби хезмәткәрләр һәм чит ил халкы яши. Бу рәвешле шәһәр, татарларның төп эшчәнлеге булган сәүдә – тукымалар, кием сату сәүдәсе белән үзенә җәлеп итә. Токиода төрки-татарлар сәүдә өлкәсендә генә түгел, хәтта Японияне тышкы сәясәтендә дә зур роль уйный.

Токиода татар җәмәгатьчелеге 1919-1921 елларда урнаша башлый. 1919-1940 елларда, төрек-татар җәмәгатьчелегенең актив эшчәнлеге чорында, вәкилләрнең саны 350-450 кешегә җитә.

Татар җәмәгатьчелеге тарихы һәм бөтен мөселман дөньясы өчен – Токиода «Исламия Мәктәбе»нең барлыкка килүе мөһим вакыйга булып тора. Япония империясенең күпгасырлык яшәеше тарихында ислам тәүге тапкыр әлеге борынгы дәүләт территориясенә «аяк баса».



Укучылар «Исламия Мәктәбе» каршында уйныйлар

Исламия мәктәбе барлыкка килгәнче, Ерак Көнчыгышта ачылган татар мәктәпләрендә укыту әсбаплары һәм Коръәни Кәрим белән тәэмин итүдә проблемалар була. Бу хәлне җайга салыр өчен Харбинның (хәзерге Кытай, Маньчжуриянең тарихи территориясе) имамы типография ача, әмма аның үлеме белән бу эш туктатыла.

Шул ук вакытта Советлар Рәсәендә татар алфавитына кагылышлы реформалар (1920 елда алфавитның гадиләштерелгән варианты – яңа имлә ысулына күчү) аркасында: эмигрантларга кайсы юлдан үтәргә, дигән сорау туа. Алфавитның яңа кагыйдәләре гарәп һәм фарсы сүзләренең күптәннән килгән язылу принципларын боза. Бу – татарларны исламнан һәм язуның элеккедән килгән күпгасырлык традицияләреннән аера. Шуның өчен соңгы чиктә Маньчжурия, Япония, Финляндия һ.б. илләрдәге татар эмигрантлары яңа алфавитны кабул итмичә, искечә язуны дәвам иттерә.

Иң баштан күпсанлы проблемалар аркасында, мигрантлар чит илдә үз балаларына гыйлем бирү соравын читкә куеп торырга мәҗбүр була. Тик бу хәл балаларны диннән, милләтләреннән һәм үзләренең тамырларыннан ерагайта башлый. Бирегәге мәктәпләрдә балалар бары кытай, япон һәм рус телләрендә сөйләшүгә күчә. Япониядә туучы балалар, үзара гына түгел, әти-әниләре белән дә япон телендә аралаша башлап, татар телләрен оныта төшә. Хәтта кайбер татар гаиләләре, безгә татар теле һәм исламны өйрәнү нигә кирәк, дигән сүзләр әйтә башлый.

Дини һәм милли үзаңнарын югалтмаган кайбер ата-аналар үзләренең балаларын диннән, телдән һәм мәдәнияттән аерылып үсмәсеннәр өчен, Токиодан Харбинга җибәрә. Ә Токио белән Харбин арасы 3100 чакрымнан да артып киткән ераклык. Моннан тыш, бу ата-аналардан зур чыгымнар таләп итә. Шул рәвешле, Япониягә күченүнең башлангыч этапларында качкыннарның балалары дини тәрбия алудан һәм туган телләрендә гыйлем эстәүдән мәхрүм була.

1920 елда токияле төрки-татарлар Мәхәллә-и Исламия җәмәгатьчелегенә берләшеп, җомга намазлары үткәрә башлый. Җомга вәгазьләре һәм нәсыйхәтләре татарларның дини һәм милли бердәмлеккә җыя. Җәмәгатьчелек балаларына дини һәм милли тәрбия бирү турында тагын да күбрәк уйлана башлый.

1927 елда, Корбан мәҗлесе вакытында җәмәгатьчелек әһелләре Токиода үзләренең дини-милли мәктәпләрен ачуның кирәклеген ассызыклый. Имам һәм укытучы Габделхәй Корбангалиев (чыгышы белән башкорт кешесе, киләчәктә мөселманнарны берләштерүдә зур роль уйнаучы) бу мәсьәлә буенча Япония хөкүмәтенә мөрәҗәгать итә.

1927 елның 2 нче октябрендә Токионың Шин-Оукубо районында Хакунин Чу 266 адресы буенча урнашкан йортта, Япония хөкүмәтенең рөхсәте белән, мөселман башлангыч мәктәбе – «Исламия Мәктәбе» үз эшчәнлеген башлый. Укытулар татар телендә алып барыла, аеруча да зур игътибар ислам диненә һәм балаларга дини гыйлем өйрәтүгә бирелә.

«Исламия Мәктәбе»н Япония мәгариф министрлыгы таләпләренә тәңгәлләштергәннән соң, 1936 елның 5 декабрендә мәктәп рәсми статуска һәм моның белән бергә Япония дәүләт мәктәпләре хокукларына һәм өстенлекләренә ия була. Мәктәпнең директоры итеп Габделхәй хәзрәт Корбангалиевны билгелиләр.

*Дәвамы бар*

■ **Мөхсин Нурулла язмасы, islam-today сайтыннан тәрҗемә**

# Кеше – гөнаһ кылучан зат

**Көндәлек мәшәкатьләр безне еш кына гыйбадәт кылудан аера, ә эш һәм көнкүреш белән мәшгуль булу, шулай ук дөньяга бәйлелек бик күп игелекләр кылырга теләгебезне кире кага. Өстебездә төрле йөк булган вакытта, үзеңне тиешле күләмдә гыйбадәт кылырга ничек мәҗбүр итәргә соң?**

Сез Аллаһы каршында бурычлы. Аллаһының сезгә күрсәткән игелекләрен исәпләп карагыз. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Ул сез сораган нәрсәләрдән бөтенесен сезгә бирде. Әгәр сез Аллаһының (сезгә биргән бөтен) нигъмәтләрен саный башласагыз, аларны санап бетерә алмассыз. Һичшиксез, кеше – (үзенә бирелгән нигъмәтләр өчен шөкер кыла белмәве белән үз-үзен мәхрүмлеккә этәргән) залим, (тарлыкка төшкән чакта зарланган, муллыкта исә хакларны үтәмәгән) нигъмәт кадерен белмәүче».**

«Ибраһим», 34

Шундый ук аятьне башка сүрәдә дә очратырга мөмкин:

**«Аллаһының (сезгә биргән бөтен) нигъмәтләрен саный башласагыз, аларны санап бетерә алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – (гөнаһларны күпләп) Гафу итүче, Рәхимле».**

«Ән-Нәхел / Бал кортлары», 16:18

Беренче аять кешеләрнең золым кылуларында һәм нигъмәтләрнең кадерен белмәүдә гаепләнүе белән, икенче аять – Аллаһы Тәгаләнең Гафу итүче, Рәхимле икәнен әйткән сүзләре белән тәмамлана. Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләр санын исәпкә алсак, без аны беркайчан да санап та, лаеклы итеп җавап та кайтара алмаячакбыз, әмма Ул барыбер Үзенең мәрхәмәте һәм юмартлыгы белән безне гафу итә. Сезнең тирәдә Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрнең саны юк. Сез аларга күпләп ия һәм көн саен алардан файда аласыз. Бу, беренче чиратта, тормыш, гаилә, тән һәм җан сәламәтлеге, күрү, ишетү, баш өстендә түбә, якыннарның кайгыртуы, җылылык, электр энергиясе, көндезге яктылык һәм башкалар.

Күз алдыгызга китерегез: әгәр шул байлыкларның берсе генә булса да юкка чыкса, тормышыгыз ни дәрәҗәдә үзгәрәчәк?

**«Суыгыз җир астына китсә, сезне чишмә суы белән кем туендырыр дип уйлыйсыз?»**

«Мүлек / Патшалык», 67:30

Шушы нигъмәтләрнең берәрсен югалтсак, без Аллаһыга мөрәҗәгать итәбез. Ләкин, безнең югалткан нигъмәтебез кире кайту белән, без моны (Аллаһы Тәгаләгә шөкерне) шунда ук онытабыз. Әгәр дә самолет яшенле фронтка эләксә, пассажирлар Аллаһыдан коткару турында ялвара башлый. Җиргә исән-сау төшү белән, кешеләр барысын да онытала.

**«Сездә булган нигъмәт – Аллаһыдан. (Хәзергә моны аңлап бетермәсәгез дә) Соңыннан бер зарар кагыла калса, (котылыр өчен) Аңа гына ялварасыз».**

«Нәхел / Бал кортлары», 16:53

Ни генә эшләсәк тә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә беркайчан да лаеклы җавап (тиешенчә шөкер) кайтара алмаячакбыз. Әгәр кинәт кенә Аллаһы Тәгаләгә якынаерга теләсәгез, Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте турында уйларга бер минут булса да вакыт табыгыз.

Күзегезне йомыгыз һәм гомерлеккә сукыр калдым дип уйлагыз. Яңадан күрү мөмкинлеге булсын өчен сез нәрсәгә әзер булачаксыз? Бу гади күнегүләр сезгә Аллаһы каршында бурычларыгызны аңларга һәм Аңа рәхмәт белдерергә мөмкинлек бирәчәк.

### Аллаһы – мәрхәмәт Иясе

Сез Аллаһы каршында бик бурычлы. Гөнаһларыгызны санап карагыз. Кешеләр табигате буенча рәхмәтсез һәм гөнаһ кылучан. Әмма Аллаһы Тәгалә безгә сабырлыгы һәм гафу итүе белән җавап бирә. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Әгәр Аллаһы (гөнаһлы) кешеләрне (көферлек, ширек кушу, харамнарга бату кебек) золымнары сәбәпле (гөнаһсызларны исә гөнаһлыларның ахмаклыгы өчен шундук җәзаландырырга теләп) тотып алса, хәрәкәтләнә алган бер генә җан иясен дә җир йөзендә калдырмас иде».**

«Нәхел / Бал кортлары», 16:53

Мөэмин мөселман үзенең гөнаһлары турында уйланып, тиз арада тәүбә кылырга ашкыныр иде. Гөнаһларыгызны ешрак искә төшерегез. Бәлки, сез кемгәдер карата тәкәбберлек күрсәткәнсездер, кемгәдер авырту китергәнсездер, кешеләрне кимсеткәнсездер, алдагансыздыр, урлагансыздыр яки көнләшкәнсездер.

### Аллаһы Тәгалә гөнаһларны яшерә

Аллаһы Тәгалә сезнең гөнаһларыгызны кешеләр алдында фаш итү өчен җитәрлек нигезгә ия. Бу гөнаһларның кайберләре сезне гаиләләреннән, эшләреннән, җәмгыятьтәге ихтирамнарыннан мәхрүм итәчәк, хәтта сезне рәшәткә артына да җибәрә алыдыр. Шуңа да карамастан, Ул сезнең гөнаһларыгызны, халык алдында кылган булсагыз да, Үзенең мәрхәмәте белән яшерде. Ул сезне кабат-кабат гафу итә һәм кешеләрнең күзләрен бу гөнаһларыгызны күрсәтми. Ә кешеләр гөнаһ кылуны барыбер дәвам итә һәм Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрен оныталар.

Ләкин бу һәрвакытта да дәвам итә алмый. Аллаһы Тәгалә гөнаһларыбызны җәмәгатьчелек хөкеменә биргән бер мизгел җитәргә мөмкин. Бу безгә дәрес бирү һәм безне Үзенә якынайту өчен эшләнә.

Үзегезнең гөнаһларыгызны һәм Аллаһы Тәгалә сезгә биргән нигъмәтләрне санап карагыз, бу сезгә Аллаһы Тәгаләгә якынаерга һәм Аңа тиешле дәрәҗәдә шөкранә кылырга ярдәм итәр. Гыйбадәт кылу, игелек эшләү авыр булса, Аллаһы каршындагы бурычыгыз турында уйлагыз. Кулыгызга Коръән алыгыз, аны ешрак укыгыз һәм тиздән сезнең йөрәгегез йомшарачак.

■ **Ильдар Нигъмәтуллин**

# Нигъмәтләр өчен шөкер

Безнең берәр кайчан «минеке» дигән сүз турында уйланып караган бармы икән? Минем өем, минем хәләл җефетем, минем машина, минем эшем, минем җирем... Әмма боларның барысы да Аллаһы Тәгаләнең тәкъдире буенча эшләнгәнен оныта башладык бугай. Шуңа өстәп, Аллаһы Тәгалә безгә сулар һавасын, эчәргә сулар һ.б.ны һәрдаим биреп тора. Әмма кеше аларны да «тиешле» дип кабул итә башлады, ахры.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә:

**«Аллаһы күктән су иңдерде һәм аның белән җирне үлеменнән соң (үсемлекләр белән) җанландырды. Һичшиксез, ишетә торган кешеләр өчен боларда (Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә, чиксез гыйлеменә, өстен кодрәтенә, тиңсез хикмәтенә күрсәткән бик күп) билге (һәм дәлил) бар»**, – дип әйтә.

«Нәхел / Бал кортлары», 16:65

Чыннан да, язларын «үле» җирнең кабаттан ямь-яшел чирәм белән каплануы, кыш буе «җансыз» тоелган агачларның кабаттан шаулап яфракта булулары Аллаһы Тәгаләнең безгә күрсәткән билгеләреннән бит. Болар турында фикерләгән кеше үзенең бу дөньядагы урыны турында, аңа бирелгән нигъмәтләр турында уйлана башлый. Без беркайчан да нигъмәтләрнең санын белмәячәкбез, әмма төп нигъмәтләр – җир, су, һава, күзләр, колаклар, аякларыбыз өчен, ризыклар һәм аларны ашый алганыбыз өчен, башыбызны сәҗдәгә иеп, ягъни намаз укып, зикерләр әйтеп шөкер кылырга тиеш түгелме соң?

**«Аллаһыдан бер юмартлык һәм нигъмәт булсын дип (Аллаһы Тәгалә игелекләр белән сезне сөйдерде, начарлыкларны начар итеп күрсәтте). Аллаһы – (һәрнәрсәне) Белүче, Хикмәт иясе».**

«Хуҗурәт / Бүлмәләр», 49:8

Әгәр дә Аллаһы Тәгалә безгә нәрсәнең хәләл, нәрсәнең харам икәнен күрсәтмәгән, гөнаһлар турында гыйлем бирмәгән булса, кешелек бик күптәннән баткаклыкта булыр иде. Әмма Аллаһы Тәгаләнең тагын бер нигъмәте булып безгә изгелек һәм гөнаһ турында биргән гыйлеме дә тора. Без гөнаһлардан читләшеп, күбрәк изгелекләр кыла һәм, шул сәбәпле, Аллаһы Тәгаләгә тагын да якыная алабыз.

Аллаһы Тәгалә безне дә, сезне дә Үзенең нигъмәтләренә шөкер итүчеләрдән кылса иде.

■ **Гәбделхәким Фәсхиев**

# «Уйлар – мозг эшчәнлегеме әллә шәйтан вәсвәсәсеме?

Беркемнең дә даими рәвештә «бер үк тырмага басасы» килмидер. Шуңа күрә үзең өчен нәтиҗәләрне ясый белү мөһим. Дөрес нәтиҗәләр ясар өчен, булган хәл турындагы мәгълүматның хакыйкый булуы да мәҗбүри.

Төгәл мәгълүматы булмаган бөтен вакыйга да, ачыктан-ачык ялган булмаса да, шикле була һәм фаразларга кайтып кала. Әмма изге Коръәни Кәрим безне алардан кисәтә:

**«Ий мөэминнәр, күп гөманнан (уйлардан) сакланыгыз, тәхкыйк, кайбер гөманда гөнаһ бардыр. Вә кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, кеше гаебен эзләмәгез вә берләрегез икенчеләрегезне гайбәт кылмасын!**

«Хуҗүрат / Бүлмәләр», 49:12

### Баш миенең эшләү тәртибе

Безнең баш миенең эшләү тәртибе түбәндәгечә: әгәр дә ниндидер вакыйгаларның билгесез якларын белмәсә, ул аларны үзенең күзаллавы белән җиңел генә сурәтли башлый: «Әгәр берәрсе очрашуга соңга калган икән, димәк, ул мине кадерләми; әгәр дә бүләк бирмәсә, димәк, ул миңа акча җәлли; ишек алдында берәрсе кычкырып йөрсә - тәрбиясез кеше…» һ.б.

Кешеләр һәм вакыйгалар турында безнең нәтиҗәләр бик тиз туа. Ләкин алар нәрсәгә нигезләнгән? Бер генә вакыйга да безгә беркайчан да 100%ка ачык булмый бит:

**«Алар Аның гыйлеменнән бары Үзе теләгәнне генә беләләр…»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:255

Без бервакытта да булган вакыйга турында барысын да күрә һәм белә алмыйбыз. Аллаһы безгә чикле мәгълүматлар бирә. Әлбәттә, тикмәгә генә түгел. Безгә мәгълүм булган мәгълүмат кысаларында, без үзебезнең көч һәм вакытны файдалы итеп кулланырга тиеш: кемгәдер ярдәм итәргә, нәрсәнедер хәл итәргә булышырга, кемнедер кайгыртырга, гафу итәргә, тәүбәләр кылырга… Без бу эшләр белән үзебезне мәшгуль кылганда, вакыйгаларның безгә билгесез ягы, Аллаһы ихтыяры буенча, безнең җаваплылыкка (бу тормышта да, Ахирәттә дә) карамый торган булып чыга. Ягъни, безнең өчен ул кирәк булмаганга, ул мәгълүматлар бездән ябык та. (Юкка гына Пәйгамбәребез, мөселман үзенә кагылмаган эшләр белән кызыксынмаска тиеш, дип әйтмәгән).

Әмма без бу механизмны һәрвакытта да аңлап бетермибез. Дөресрәге, нәфесебез моны аңларга теләми, чөнки аңлаган очракта, үз ниятеңә, үз эшеңә, гөнаһларыңа игътибар итәргә кирәк бит… Тикшерер өчен синең үз эчеңдә булганнар да күп һәм инде чит кешенең үз-үзен тотышын тикшерү өчен вакыт калмаячак..

Әмма нәфесебез Аллаһы Тәгалә безгә яшергәннәрнең ни өчен яшерелгәннәрен ачыклау өчен бар көчен куя. Ә бу алдан ук уңышсыз. Һәм зарарлы, чөнки дошман булган шәйтан безне гөнаһка этәрер өчен җай гына көтә. Бу очракта - нигезсез уйларга һәм ялган булган фаразларга таянабыз.

■ **Гүзәл Ибраһимова**

# Бу нәрсә дигән сүз?

Кеше, кагыйдә буларак, аңа берәр нәрсә ошамаса, борчылырга мәҗбүр итсә, уйлана, фаразлар төзи башлый. Безне барысы да канәгатьләндергәндә, без төрле «нигә, ни өчен» кебек сорауларда «казынырга» яратмыйбыз.

Безнең эшләрдә чит кеше аркасында берәр гаеп булса, безгә башка шартларда эш итәргә туры килә (без чыннан да үзебезгә караган эш белән мәшгуль була алабыз). Хәзер бездән яңа карарлар эзләүгә көч таләп ителә. Әгәр моңа мөмкин кадәр тизрәк керешсәк, без шунда ук файдалы эшкә керешәчәкбез. Шул рәвешле, баш миенең потенциалын файдалы якка күчерәбез: безгә бу мәшәкатьне чишү юлларын эзләү кирәк була һәм кешенең гаебен эзләргә вакыт калмаячак.

Эшләребезнең барышын, кемнең дә булса гамәле яки сүзе аша, Аллаһы Тәгалә Үзе үзгәртүен аңлау мөһим… Шушы чит кешенең гамәлендә Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры яткапын күреп, Аннан ярдәм һәм шәйтаннан яклавын сорагач, без алга таба хәрәкәт итә алачакбыз.

Һәм хәтта көтелмәгән үзгәрешләр өчен дә Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт белдерүчеләр табылачак. Пәйгамбәребез: «Мөэмингә нинди генә кайгы, борчу яки бәла-каза килмәсен, хәтта энә кадавы да, бу аның гөнаһларын йолу булачак», – дип әйткән (Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

### Моның куркынычы нәрсәдә?

Шәйтанны кешене тикшеренүләргә һәм (Ни өчен шулай эшләде? Ничек булдыра ала ул? һ.б.) фаразларга гына батыру туктатмый. Ул кешене алга таба – шикләнүләргә һәм кешене нахакка гаепләүләргә этәрә. Менә шуннан соң теге надан, монысы комсыз, өченчесе хәйләкәр һ. б. кебек уйлар килә башлый.

Мондый гаепләүләр башка кешенең – Аллаһы колының дәрәҗәсенә турыдан-туры кагыла бит. Аллаһы Тәгалә аны барлыкка китергән, Ул аны кайгыртып, тора, ә кемдер аның турында ялган фаразлар төзи, начар ярлыклар тага, нигезсез рәвештә гаепли башлый. Бу турыда теге кеше бернәрсә дә белмичә, ишетмичә калса да, бу аның шәхесенә, тормышына кул сузу була. Үз колының дәрәҗәсен кимсеткән кешегә Аллаһы Тәгалә ничек булыр икән?

Онытмыйк, без үзебез дә Аллаһының коллары. Безне дә Ул яклый һәм ярата, Аңа мактау булсын. Шуңа күрә ниндидер мизгелдә Аллаһы Тәгалә безгә «гаепленең» гаепсез икәнлеген белергә рөхсәт итә ала. Ул чагында, без кеше турында начар уйлаганыбыз өчен үкенергә мөмкинлек алачакбыз, һәм шул рәвешле аз булса да гаебебезне йолабыз.

Әгәр дә тәүбәгә килмәсәк яки Аллаһы Тәгалә безгә бу кешенең гаебе юклыгын ачмаса? Ул чагында безнең хисабыбыз Кыямәт көненә күчәчәкме? Ә бит анда һәр фараз безне күп тапкырлар гаепле итә ала…

Бу тормышта без кешеләрнең теге яки бу гамәлне нәкъ шул рәвешле башкарырга ни этәргәнен белә алмыйбыз (кеше үзе дә һәрвакытта да бу хакта уйлап бетерми). Безнең өчен иң дөресе – Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылырга өйрәнеп, фаразлардан һәм төрле уйлардан арыну. Чөнки тормыш кешеләр турында «начар уйлап, ялгышканга караганда, алар турында яхшы уйлап, ялгышу» хәерлерәк икәнен үзе үк дәлилли.

■ **Гүзәл Ибраһимова**

# Тәкъва булырга вакыт түгелме?

Без һәр көнне теге кешенең бу премияне алуын, бу кешенең шуның кадәр акча эшләвен ишетеп торабыз. Беребез Җир шарының көньягында, беребез – төньягында. Кемдер Аллаһы Тәгалә тәкъдире белән озын, кемдер кыска гомер кичерә.

Чыннан да, дөньяда ниләр генә бармый. Ул – кайный. Ул кайнаган арада без шунда кайнаганнарны «чәйнәп» гайбәтләрен сөйләп алырга өлгерәбез, калганнар безне «чәйни».

Әмма адәм өчен яшәү кагыйдәләре күптән билгеле – ул Коръән һәм Сөннәт юлы. Шуңа күрә дә андагы кагыйдәләрне өйрәнсәк, үз вакытыбызны шуларга бүлеп бирсәк иде. Ул чакта вакытыбыз, яшәгән көннәребез әрәм, исраф түгел, ә гыйбадәттә үткән булып язылачак.

### Без кемнән өстен?

Кагыйдә буларак, әгәр дә без берәр кешенең гайбәтен сөйләсәк, без тизрәк үзебезгә аклану эзли башлыйбыз: мин яхшы, ә менә ул… Кешенең нинди дә булса бер гаебен тартып чыгарып, үзебезне өстен куябыз. Әмма бу чыннан да шулаймы соң? Без кемнән өстен була алабыз? Аллаһы Тәгалә бу турыда Коръәни Кәримдә:

**«Тәхкыйк, сезнең Аллаһы хозурында хөрмәтлерәгегез – Аллаһыдан куркучыгыз, тәкъва булганыгыз», – дип әйтә.**

«Хуҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

Кем үзен тәкъва дип саный? Кем үзен чыннан да Аллаһыдан тиешле курку белән курка дип уйлый? Чыннан да тәкъва булган кешенең калганнарның гайбәтен сөйләргә вакыты юк, ә инде бу гамәлгә вакыты булганнарга сорау: тәкъва булырга вакыт түгелме?

■ **Гәбделхәким Фәсхиев**

# Аллаһы белән очрашуны көтүче



Факыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди радыяллаһу ганһе әйтүенчә, Мөхәммәд бине Фазыл үзенең иснәде белән Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһедән риваять итә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Берәү Аллаһы Тәгаләгә юлыгуны, ягъни Ахирәт йортына кайтуны сөйсә, Аллаһы да аның белән очрашуны сөяр, аңа мәрхәмәтле булыр, аны күпсанлы нигъмәтләре белән бүләкләр. Ә инде Аллаһы белән очрашуны теләмәгән кеше белән Аллаһы Үзе дә очрашырга теләмәс. Дөреслектә, кяфер кеше үзенә әзерләнгән җәзаларны күргәннән соң, адашуда булганы өчен үкенер. Аллаһы аны Үзенең рәхмәтеннән һәм нигъмәтләреннән ераклаштырыр».

# Ахирәт газабы дөнья газабыннан катырак

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйтте: «Бер кеше үлемне анык һәм хакыйкатьтә үлем аңа һичшиксез иңәчәк икәнен белсә, аңа үлем өчен изге гамәлләр кылу һәм яман эшләрдән саклану белән әзерләнүдән чара юк, чөнки ул кеше кайчан үлем ирешәчәген белми. Тәхкыйк Расүлебез галәйһиссәлам үзенең өммәтенә үгет йөзеннән, үлемгә әзерләнсеннәр һәм дөньяның катылыкларына түзсеннәр өчен үлемнең катылыгын һәм ачылыгы бәян кылды. Дөреслектә, дөньяның катылыкларын түзү үлем катысыннан җиңелрәктер, Ахирәт газабы дөнья газабыннан катырактыр».

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам үлем өчен әзерләнүне бәян кылды: «Хакыйкатьтә үлемгә әзерләнү гыйлемнең башыннандыр, үлемгә әзерләнү белән мәшгуль булу – беренчедер».

# Мәңге кала торган йорт

Габдулла бине Әл-Мөсәүвир Әл-Һәшими риваять итте. Габдулла радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу аятьне укыды: «Аллаһы Тәгалә бер кешене туры юлга күндерүне теләсә, ул кешенең күкрәген Ислам өчен ачар. Бер кешене аздырырга теләсә, аның күкрәген тар һәм мәшәкатьле кылыр». Моннан соң Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Әгәр күңелгә Ислам нуры керсә күңеле киң булып ачылыр». Аннан: «Моның өчен галәмәт булырмы?» – дип сорадылар. Пәйгамбәребез: «Алдау йортыннан ерак булу һәм мәңге кала торган йортка ышану, үлем ирешкәнгә кадәр үлемгә әзерләнү», – дип әйтте.

# Ләззәтләрне сындыручы зикер

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән Әбү Сәгыйд Әл-Хөдри радыяллаһу ганһе риваять итә. Пәйгамбәребез көлүче кешеләрне күреп, болай дип әйтте: «Әгәр үлемнән зикерне күп кылсагыз, мин күргән нәрсәдән шөгыльләнүегез өчен сезгә ни булыр?» Аннан соң: «Ләззәтләрне сындыручы зикерне, ягъни үлемне күп искә алыгыз», – диде. Шулай ук: «Дөреслектә кабер – ул җәннәт бакчаларыннан бер бакча яки ут чокырларыннан бер чокырдыр», – дип әйтте.

# Биш кыйммәтле әйбер

Җәгъфәр бине Бәрканнан, ул Мәймүн бине Мәһраннан риваять итә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез бер ирне вәгазьләп, болай дип әйтте: «Биш нәрсәдән әүвәл биш нәрсәне: картаймастан әүвәл яшьлегеңне, авырганнан әүвәл сәламәтлегеңне, шөгылеңнән әүвәл буш вакытыңны, фәкыйрьлегеңнән әүвәл байлыгыңны, үлемнән әүвәл тереклегеңне ганимәт дип бел». Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бу биш нәрсәдә күп гыйлемне җыйды, чөнки ир картайган хәлдә кодрәтле булмаган нәрсәгә егет булганда кодрәтлерәк була. Яшь кеше гөнаһ кылуга гадәтләнсә, картайганнан соң ул гөнаһтан тыелырга көче җитмәс. Егет кеше картлык көнендә үзенә җиңел булсын өчен яшь вакытында изгелекләрне кылырга гадәтләнергә тиеш. «Авырудан әүвәл сәламәтлегеңне» дигән сүз шуның өчендер, сау кешегә үзе һәм малы белән эшне үтәү тиешле була. Сәламәтлекне ганимәт дип белү, изге гамәлләрдә үзенең малы һәм тәне белән тырышу, чөнки ул кеше авырса, аның тәне тәгатьтән зәгыйфьләнә, малыннан кулы кыскара, мәгәр өчтән бер өлешендә генә. «Шөгылеңнән әүвәл буш вакытыңны» дигән сүзнең мәгънәсе, ягъни кичен буш, көндезен шөгыльле бул. Кичләрен намаз укырга, көндезен шөгыль вакытында ураза тотарга тиеш була, бигрәк тә кыш көннәрендә.

# Мөэмингә йомшаклык кылучы зат

Гали радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Дөреслектә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бер ансар кешесенең баш турысында үлем фәрештәсен күреп, «минем иптәшемә йомшак бул, дөреслектә, ул кеше мөэминдер», – дип әйтте. Фәрештә болай дип җавап бирде: «Әй, Мөхәммәд, сөенеч бир, дөреслектә мин һәр мөэмингә йомшаклык кылучымын. Әй, Мөхәммәд, Аллаһы белән ант итеп әйтәм, дөреслектә, мин адәм баласының җанын алам. Шулвакытта ул адәм баласының әһеленнән бер кычкыручы кычкырыр, моны кычкыручы дип әйтермен. Валлаһи, ул кешегә золым китермәм, ул кешенең әҗәлен элек кылмадык, аның тәкъдирен ашыктырмадык. Безгә аны алуда гөнаһтан ни булыр? Аллаһы Тәгалә эшләгән нәрсәгә разый булсагыз, әҗерле булырсыз, кайгырсагыз яки сабырсызлык кылсагыз, гөнаһлы булырсыз. Безнең каршыда сезнең өчен шелтәдән башка һичнәрсә юк. Дөреслектә, безнең өчен сезнең хозурыгызга аңсызлык һәм кайтмау булучыдыр. Йорт әһелләреннән йон яки тузан пәрасе кырда, кирәк диңгездә булса һич нәрсә юк, камил саклану белән сакланыгыз, мәгәр мин һәр кич һәм көндезен биш мәртәбә аларның йөзләренә сугармын, хәтта мин аларның үзләрен кечкенәләрен һәм олугларын беләм. Әй Мөхәммәд! Аллаһы белән ант итеп әйтәм, әгәр мин чебен җанын алырга теләсәм, Аллаһы Тәгалә ул рухны алу белән Үзе боеручы булганга, минем моңа көчем җитмәс».

# Үлем – мөэминнең рәхәтедер

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә. Дөреслектә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Үлем мөэминнең рәхәтедер».

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһе Рәсүлебездән риваять итә. Дөреслектә Пәйгамбәребездән: «Кайсы мөэминнәр артыгырак?» – дип сорадылар. Ул: «Холык йөзеннән иң күркәме», – дип җавап бирде. Аннары кабат: «Кайсы мөэмин-нәрнең янчыклары тулырак?» – дигән сорау бирелде. Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Үлемне күп зикер итүче һәм ул үлем өчен әзерләнү йөзеннән аларның күркәмрәге», – дип әйтте.

Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Зирәк кеше үзен таныган һәм үлемнән соң булган нәрсәгә гамәл кылган кешедер. Фәҗир (гөнаһлы) кеше – ул нәфесенә һәм нәфес теләкләренә иярер, Аллаһы Тәгаләдән котылуны, ягъни ярлыкауны теләр».

*«Тәнбиһүл-гафилин» китабыннан*

## Дүшәмбе

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Бер мәчет тарихы
10:00 «Барбаросса» мультфильм
10:20 Бәрәкәтле гаилә
11:00 Минем Рамазан
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Хикмәтле хикәяләр
11:45 Мукабалә (Чтение Священного Корана)
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 «Барбаросса» мультфильм
12:50 Поучительные истории
13:00 «Малец-Удалец» мульт-фильм
13:10 Исламские финансы
13:30 Готовимся к Рамадану
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
17:30 «Мәслихәт»
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 Бер мәчет тарихы
19:00 «Барбаросса» мультфильм
19:20 Бәрәкәтле гаилә
20:00 Минем Рамазан
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Хикмәтле хикәяләр
20:45 Мукабалә (Чтение Священного Корана)
21:00 Сказки снов
21:10 «Малец-Удалец» мульт-фильм
21:20 Маленькие взрослые
21:30 «Барбаросса» мультфильм
21:50 Исламские финансы
22:10 Готовимся к Рамадану
22:20 МИМ
22:30 Поучительные истории
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

## Сишәмбе

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Балам-багалмам
08:20 Минем Рамазан
08:30 Хәзинә
08:45 1001 хәзинә
09:00 «Барбаросса» мультфильм
09:20 МИМ
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:40 Хикмәтле хикәяләр
09:50 Бер хәдис - бер җавап
10:00 Намазга өйрәник
10:20 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
10:40 Гаилә дәресләре
11:05 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:20 «Тәфсир дәресләре» Тимергали Юлдашев
11:50 Мукабалә (Чтение Священного Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:15 «Малец-Удалец» мульт-фильм
12:30 «Барбаросса» мультфильм
12:50 Готовимся к Рамадану
13:00 Мастерская мусульманки
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Балам-багалмам
17:20 Минем Рамазан
17:30 Хәзинә
17:45 1001 хәзинә
18:00 «Барбаросса» мультфильм
18:20 МИМ
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:40 Хикмәтле хикәяләр
18:50 Бер хәдис - бер җавап
19:00 Намазга өйрәник
19:20 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
19:40 Гаилә дәресләре
20:05 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:20 «Тәфсир дәресләре» Тимергали Юлдашев
20:50 Мукабалә (Чтение Священного Корана)
21:00 Сказки снов
21:10 Ученые ислама
21:30 Готовимся к Рамадану
21:45 Актуальный ислам
22:00 Мастерская мусульманки
22:10 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
22:30 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

## Чәршәмбе

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
08:30 «Мәслихәт»
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Бер мәчет тарихы
10:00 «Барбаросса» мультфильм
10:20 Бәрәкәтле гаилә
11:00 Минем Рамазан
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Хикмәтле хикәяләр
11:45 Мукабалә (Чтение Священного Корана)
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 «Барбаросса» мультфильм
12:50 Поучительные истории
13:00 «Малец-Удалец» мульт-фильм
13:10 Исламские финансы
13:30 Готовимся к Рамадану
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
17:30 «Мәслихәт»
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 Бер мәчет тарихы
19:00 «Барбаросса» мультфильм
19:20 Бәрәкәтле гаилә
20:00 Минем Рамазан
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Хикмәтле хикәяләр
20:45 Мукабалә (Чтение Священного Корана)
21:00 Сказки снов
21:10 «Малец-Удалец» мульт-фильм
21:20 Маленькие взрослые
21:30 «Барбаросса» мультфильм
21:50 Исламские финансы
22:10 Готовимся к Рамадану
22:20 МИМ
22:30 Поучительные истории
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

## Пәнҗешәмбе

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Балам-багалмам
08:20 Минем Рамазан
08:30 Хәзинә
08:45 1001 хәзинә
09:00 «Барбаросса» мультфильм
09:20 МИМ
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:40 Хикмәтле хикәяләр
09:50 Бер хәдис – бер җавап
10:00 Намазга өйрәник
10:20 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
10:40 Гаилә дәресләре
11:05 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:20 Тәфсир дәресләре Тимергали Юлдашев
11:50 Мукабалә (Чтение Священного Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:15 «Малец-Удалец» мульт-фильм
12:30 «Барбаросса» мультфильм
12:50 Готовимся к Рамадану
13:00 Мастерская мусульманки
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Балам-багалмам
17:20 Минем Рамазан
17:30 Хәзинә
17:45 1001 хәзинә
18:00 «Барбаросса» мультфильм
18:20 МИМ
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:40 Хикмәтле хикәяләр
18:50 Бер хәдис - бер җавап
19:00 Намазга өйрәник
19:20 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
19:40 Гаилә дәресләре
20:05 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:20 Тәфсир дәресләре Тимергали Юлдашев
20:50 Мукабалә (Чтение Священного Корана)
21:00 Сказки снов
21:10 Ученые ислама
21:30 Готовимся к Рамадану
21:45 Актуальный ислам
22:00 Мастерская мусульманки
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
22:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

## Җомга

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
08:30 «Мәслихәт»
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Бер мәчет тарихы
10:00 «Барбаросса» мультфильм
10:20 Бәрәкәтле гаилә
11:00 Минем Рамазан
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 «Минбар» Җомга вәгазе
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 «Барбаросса» мультфильм
12:50 Поучительные истории
13:00 «Малец-Удалец» мульт-фильм
13:10 Исламские финансы
13:30 Готовимся к Рамадану
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
17:30 «Мәслихәт»
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 Бер мәчет тарихы
19:00 «Барбаросса» мультфильм
19:20 Бәрәкәтле гаилә
20:00 Минем Рамазан
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Җомга вәгазе
21:00 Сказки снов
21:10 «Малец-Удалец» мульт-фильм
21:20 Маленькие взрослые
21:30 «Барбаросса» мультфильм
21:50 Исламские финансы
22:10 Готовимся к Рамадану
22:20 МИМ
22:30 Поучительные истории
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

## Шимбә

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 Минем Рамазан
08:30 Балам-багалмам
08:50 МИМ
09:00 «Барбаросса» мультфильм
09:20 Хикмәтле хикәяләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Һөнәрләр
10:00 Хәзинә
10:15 Әлифба сабаклары
10:30 Намазга өйрәник
10:50 «Мәслихәт»
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:45 Мукабалә (Чтение Священного Корана)
12:00 Азан
12:05 «Малец-Удалец» мульт-фильм
12:20 Маленькие взрослые
12:30 «Барбаросса» мультфильм
12:50 Готовимся к Рамадану
13:00 Исламские финансы
13:20 Учимся читать намаз
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 Минем Рамазан
17:30 Балам-багалмам
17:50 МИМ
18:00 «Барбаросса» мультфильм
18:20 Хикмәтле хикәяләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 Һөнәрләр
19:00 Хәзинә
19:15 Әлифба сабаклары
19:30 Намазга өйрәник
19:50 «Мәслихәт»
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:45 Мукабалә (Чтение Священного Корана)
21:00 «Малец-Удалец» мульт-фильм
21:15 Маленькие взрослые
21:30 «Барбаросса» мультфильм
21:50 Готовимся к Рамадану
22:00 Исламские финансы
22:20 Учимся читать намаз
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

## Якшәмбе

07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 Минем Рамазан
08:30 Балам-багалмам
08:50 МИМ
09:00 «Барбаросса» мультфильм
09:20 Хикмәтле хикәяләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 Һөнәрләр
10:00 Хәзинә
10:15 Әлифба сабаклары
10:30 Намазга өйрәник
10:50 «Мәслихәт»
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 «Минбар» Җомга вәгазе
12:00 Азан
12:05 «Малец-Удалец» мульт-фильм
12:20 Маленькие взрослые
12:30 «Барбаросса» мультфильм
12:50 Готовимся к Рамадану
13:00 Исламские финансы
13:20 Учимся читать намаз
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 Минем Рамазан
17:30 Балам-багалмам
17:50 МИМ
18:00 «Барбаросса» мультфильм
18:20 Хикмәтле хикәяләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 Һөнәрләр
19:00 Хәзинә
19:15 Әлифба сабаклары
19:30 Намазга өйрәник
19:50 «Мәслихәт»
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 «Минбар» Җомга вәгазе
21:00 «Малец-Удалец» мульт-фильм
21:15 Маленькие взрослые
21:30 «Барбаросса» мультфильм
21:50 Готовимся к Рамадану
22:00 Исламские финансы
22:20 Учимся читать намаз
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

## «Хозур» нәшрият йорты Җәлил хәзрәт Фазлыевның «Күңел бакчасы» дип исемләнгән китабын нәшер итте




Татарстан Республикасының баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның әлеге китабында гаилә кору, мөселман гаиләсе, гаиләне саклау мәсьәләләре күтәрелә. Беренче өлештә автор бәхетле һәм бәрәкәтле гаиләнең нигезе иман булуын ассызыклый, һәр гаиләнең Аллаһы Тәгалә ризалыгын алырлык итеп яшәвен тели.

Китапның икенче өлешендә Локман Хәким нәсыйхәтләре бәян ителә. Локман Хәким Давыт галәйһиссәлам вакытында яшәгән булса да, нәсыйхәтләрендә күтәрелгән мәсьәләләр бүгенге көн өчен дә бик актуаль. Алар безне уйланырга мәҗбүр итә, тормышыбызга башка күзлектән карарга мөмкинлек бирә.

Өченче өлештә автор укучыны үзенең остазлары белән таныштыра. Алар мисалында мөселман гаиләсе, тәрбия, ата-ана һәм бала мөнәсәбәте кебек темаларны киңрәк ача.

Әлеге китапны «Хозур»ның фирма кибетеннән һәм интернет аша да алырга мөмкин:
**Кибет:** Казан, Тукай ур., 36.
Тел.: +7 (903) 305-45-43
**Склад:** Казан, Газовая ур., 14.
Тел.: +7 (966) 250-00-09
**Интернет кибет:** huzurshop.ru/




### КАЗАН ӨЧЕН АПРЕЛЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.04.2020 | 02:58 | 03:43 | 05:13 | 12:00 | 15:18 | 16:12 | 18:22 |
| 02.04.2020 | 02:55 | 03:41 | 05:11 | 12:00 | 15:19 | 16:14 | 18:24 |
| 03.04.2020 | 02:51 | 03:38 | 05:08 | 12:00 | 15:20 | 16:15 | 18:26 |
| 04.04.2020 | 02:48 | 03:35 | 05:05 | 12:00 | 15:22 | 16:17 | 18:28 |
| 05.04.2020 | 02:44 | 03:33 | 05:03 | 12:00 | 15:23 | 16:18 | 18:30 |
| 06.04.2020 | 02:41 | 03:30 | 05:00 | 12:00 | 15:24 | 16:19 | 18:32 |
| 07.04.2020 | 02:37 | 03:28 | 04:58 | 12:00 | 15:25 | 16:21 | 18:34 |
| 08.04.2020 | 02:33 | 03:25 | 04:55 | 12:00 | 15:26 | 16:22 | 18:36 |
| 09.04.2020 | 02:29 | 03:22 | 04:52 | 12:00 | 15:27 | 16:24 | 18:38 |
| 10.04.2020 | 02:26 | 03:20 | 04:50 | 12:00 | 15:28 | 16:25 | 18:40 |
| 11.04.2020 | 02:22 | 03:17 | 04:47 | 12:00 | 15:29 | 16:27 | 18:42 |
| 12.04.2020 | 02:18 | 03:15 | 04:45 | 12:00 | 15:30 | 16:28 | 18:44 |
| 13.04.2020 | 02:14 | 03:12 | 04:42 | 12:00 | 15:31 | 16:29 | 18:46 |
| 14.04.2020 | 02:10 | 03:10 | 04:40 | 12:00 | 15:32 | 16:31 | 18:48 |
| 15.04.2020 | 02:06 | 03:07 | 04:37 | 12:00 | 15:33 | 16:32 | 18:50 |
| 16.04.2020 | 02:01 | 03:05 | 04:35 | 12:00 | 15:34 | 16:33 | 18:52 |
| 17.04.2020 | 01:57 | 03:02 | 04:32 | 12:00 | 15:35 | 16:35 | 18:54 |
| 18.04.2020 | 01:53 | 03:00 | 04:30 | 12:00 | 15:36 | 16:36 | 18:56 |
| 19.04.2020 | 01:48 | 02:57 | 04:27 | 12:00 | 15:37 | 16:37 | 18:58 |
| 20.04.2020 | 01:44 | 02:55 | 04:25 | 12:00 | 15:38 | 16:39 | 19:00 |
| 21.04.2020 | 01:39 | 02:53 | 04:23 | 12:00 | 15:39 | 16:40 | 19:02 |
| 22.04.2020 | 01:34 | 02:50 | 04:20 | 12:00 | 15:40 | 16:41 | 19:04 |
| 23.04.2020 | 01:29 | 02:48 | 04:18 | 12:00 | 15:40 | 16:43 | 19:06 |
| Рамазан аеның беренче көне | | | | | | | |
| 24.04.2020 | 01:24 | 02:45 | 04:15 | 12:00 | 15:41 | 16:44 | 19:08 |
| 25.04.2020 | 01:19 | 02:43 | 04:13 | 12:00 | 15:42 | 16:45 | 19:10 |
| 26.04.2020 | 01:13 | 02:41 | 04:11 | 12:00 | 15:43 | 16:46 | 19:12 |
| 27.04.2020 | 01:07 | 02:38 | 04:08 | 12:00 | 15:44 | 16:48 | 19:14 |
| 28.04.2020 | 01:01 | 02:36 | 04:06 | 12:00 | 15:45 | 16:49 | 19:16 |
| 29.04.2020 | 00:54 | 02:34 | 04:04 | 12:00 | 15:46 | 16:50 | 19:18 |
| 30.04.2020 | 00:47 | 02:32 | 04:02 | 12:00 | 15:47 | 16:51 | 19:20 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Март саны, №3 (296)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъват бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2747
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 24 нче мартта таратыла.
График буенча бу санга 23 нче март көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.